www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 3 (1419) 27 гыйнвар 2023 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

2

Күптән түгел халыкка ачылган җанисәп нәтиҗәләре шаккатырды һәм кайсы юнәлештә эш җитенкерәмәгәнен анык күрсәтте.

12

Елның тәүге сәяхәтендә илнең төньяк башкаласында татар тарихын, татар эзләрен барлап, бүгенге вәзгыять турында фикерләдек.

14

Башкортстанның Борай районында туып үскән рәссам Чулпан Билалова иҗатында төрле сәнгати юнәлешләр чагылыш таба.

Кышкы аклык тынлыгында Шау-гөр килгән мәлебез...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Мәгърифәтче галим, атаклы дин әһеле Шиһабетдин Мәрҗанинең 205 еллыгы уңаеннан, Әтнәдә аның музеенда «Мөселман хатын-кызларының гаиләдә һәм җәмгыятьтә әһәмияте» дигән кичә үтте.
- Дүртөйледә Башкортстанның халык шагыйре Наҗар Нәҗми исемендәге «Очыш өчен канатлар бар» шигъри фестиваль-конкурсы узачак.
- Җиде дәүләтнең 25 университеты һәм институтыннан 34 белгеч катнашындагы галимнәр коллективы «IV-XII гасырларда Төрки дөнья» фәнни монографиясенең беренче томын әзерләгән.
- Башкорт опера һәм балет театрының сәнгать җитәкчесе, Россиянең атказанган артисты, Башкортстанның халык артисты Әскәр Абдразаков Россия Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет составына керде.
- Түбән Камадагы Әхсән Фәтхетдинов музеенда Чаллы һәм Менделеевск рәссамнарының «Татарстанны данлап» дип исемләнгән күргәзмәсе ачылды.
- Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе итеп кабат Зилә Вәлиева сайланды.
- Зәй районының Түбән Биш авылында язучы Рабит Батулланың музее оештырыла.
- 1 февральдән Россия ислам институтында «Без – татарлар» проекты кысаларында бушлай татар теле курслары башлана.
- «Мирас» фестивале кысаларында яшь композитор Миләүшә Хәйруллинаның «Кави-Сәрвәр» операсы күрсәтеләчәк.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Язучылар берлеге рәисе:

«Яһүд белән татар ничек аерыла? Яһүдләр бөтен дөньяга таралган, алар капиталын да Израильгә күчерергә омтылып тора, үз халкына рухи яктан да ярдәм итә. Бездә киресенчә: нәрсәнедер гел Казаннан өмет итәләр, концерт киемнәреме ул һ.б. Безнең күңелне күтәрер өчен генә, «укытучы да җибәрегез» ди әле читтәге татарлар. Аларга, бәлкем, укытучы да кирәкмидер, дигән хис кала».

СЫНАМЫШЛАР

28 гыйнварда аяз булса, яз бик матур килә ● Гыйнвар салкын булса, июль коры һәм эссе була ● Гыйнвар җылы килсә, март салкын була ● Гыйнварда еш буран котырса, җәй яңгырлы була ● Гыйнварның икенче яртысында көннәр кояшлы булса, игеннәр уңа ● Гыйнварда суыграк булган саен, җәен боз яву ихтималы кимрәк ● Гыйнварда суык һәм коры булса, яз көне кар тиз эреп бетә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 48 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 05 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **8 сәгать 17 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **27 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **3 февральдә 8 сәгать 44 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

27 гыйнвар – театр белгече, педагог, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Рауза Фатих кызы Усманованың тууына 100 ел (1923–2014);

– Бөтендөнья холокост корбаннарын искә төшерү көне.

29 гыйнвар – актёр, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәрим Ибраһим улы Гыйльмановның тууына 110 ел (1913–1964).

31 гыйнвар – Бөтендөнья фокусчылар көне.

1 февраль – режиссер, педагог, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рөстәм Мулланур улы Фәткуллинга 65 яшь (1958).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Гыйнвар-февральнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 1 февраль.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(28 гыйнвар-5 февраль)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рәҗәб аеның 5 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Вахит ИМАМОВ

ХИЛАФ ҖАНИСӘП

Әүвәл 2020 елга билгеләнгән җанисәп алуны коронавирус дигән зәхмәт аркасында 2021 елга күчергәннәр иде, аның үтеп китүен сизүче дә булмады. Менә, узган ел ахырында ул җанисәп нәтиҗәләрен игълан иткән булдылар, ил буенча иң беренче чиратта татар халкы аркасына ауды. Шаккатмаслык түгел, илдәге халык саны да үзгәрмәгән, имеш, урыс милләте дә нәкъ элекке рәвештә үк чәчәк ата, ә татар халкының менә берьюлы 600 меңе юкка чыккан икән, янәсе. Бу мәгълүматларның шыр уйдырма булуы шаккатырмый калмый. 1990 елгы «демократик» түнтәрештән бирле илдәге матбугат чаралары ничәмә-ничә йөз мәртәбә Россиядә халык саны кимү турында сөрән салып һәм чаң сугып барды, дистәләгән матбугат 30 ел дәвамында чит илгә күченгән качаклар санын хәтта 30 миллионга тиңләде. Россиядә ел саен вафат булучылар санының бер миллионга җитүе турында да никадәрле бугаз ярдылар. 2010 елгы җанисәп үтеп киткәч, Үзәк статистика идарәсенең бер бүлек мөдире Россиядә русларның 89 миллионнан артык түгеллеген игълан итеп чыкты, аны шундук эшеннән алдылар. Ә быелгы мәгълүматларында һичнинди үзгәреш юк: безнең «өлкән агай» һаман элеккечә – 105 миллион булып гөрли икән ләбаса! Ел саен бер миллион кеше чит илләргә, янә бер миллионы фани дөньяга күчеп торгач, ничек һаман арта, ничек үсә икән? – мәңге аңламаслык. Тютчев: «Умом Россию не понять!» – дип юкка гына әйтмәгәндер инде.

Россиядәге гомумхалык саны соңгы ун ел эчендә биш миллионга арткан, дип тәкрарлыйлар. Бер өлешенә ышанырга да була, 2014 елда Кырым ярымутравы кушылды, Донбасс белән Луганск өлкәсеннән дә өч миллион чамасы кеше «канат астына» күчерелде. Анныры Төньяк Кавказдагы милләтләрнең саны искиткеч тиз арта. Мисалга, чеченнәр ун елда - 241, ингушлар 73 меңгә арткан. Алардан тыш, Россиянең байтак калаларын үзбәк, таҗик, кыргыз күчмәннәре басып алды, алар арасыннан байтак гастарбайтер Россия паспортлары алып эшкә керә, менә шулар хисабына илдәге халык санының берникадәр дәрәҗәдә артуы да мөмкин. Алар өстенә, безнең урамнарда хәзер вьетнамлы, кореялы кешеләр дә, кытай белән негрлар да бик аз түгел инде.

Урыс арта, бер уйласаң, гаҗәп тә түгел кебек. Иллә мәгәр шул ук илдә, бер үк шартларда яшәүче чуаш, мари, мордва, удмурт, башкорт халкы нишләп кимегән соң? Алардан да бигрәк, татар милләтенең кимүе мөмкинмени?

Саннарга күз йөгертик. Татарстанның үзендә татарлар саны ун ел эчендә 78 мең кешегә арткан – монысы бик нормаль. Ләкин менә Татарстандагы урыслар саны шул ук дәвердә 218 меңгә арткан, дип күрсәтелә. Татарларның унар яки иллешәр мең булып, бер илгә дә чыгып качканы юк, ә үсеш аермасы зур бит. Ә инде чит өлкәләргә күчсәң, бөтенләе белән эт – баш, сыер – аяк. Чиләбе өлкәсендәге татарлар саны – 60, Свердловск өлкәсендә – 50, Ульян өлкәсендә – 38, Пермьдә – 23, Мордовиядә – 8, Төмән өлкәсендә 6 меңгә кимегән, имеш. Ә Байкал арты, Амур, Нижгар, Кострома, Иваново, Приморье, Владимир, Хабаровск өлкәләрендә – 2 тапкыр, Коми республикасында фәкать татар халкы гына ике тапкыр ярым кимегән. Ленинград өлкәсендә татарлар – 22 процентка, Санкт-Петербургның үзендә 35 процентка, ә башкалабыз Мәскәүдә хәтта 40 процентка кимегән, дип раслыйлар. Нинди ясалма саннар белән эш итү бу? Татар хатыннары түшәкләре өстенә тимер челтәр корып куйганмыни?..

Фәкать татар халкына карата гына саннар геноцидының сере бик тирәндә түгел. Татар халкы Россиядә сан ягыннан руслардан гына калыша һәм иң мөһиме – татар милләте бүген дә ил буенча иң белемле халык. Бездә һәр биш кешенең берсе югары белемле, татарның дөньякүләм танылган галимнәре дә хәтсез. Аннан да мөһимрәге – татар, руслардан кала, Россия күләмендә элек әллә ничә мөстәкыйль дәүләт тоткан бердәнбер милләт. Безнең йөрәкләрдә яңадан да хөр вә азат булу хыялы күмер сыман пыскый, аны бернинди полиция яки жандармерия көчләре белән дә изеп ташлап булмый. Генерал Краснов, адмирал Колчак яки генерал Деникин кебек бердәм һәм бүленмәс Россия турында хыялланган карагруһчы көчләргә иң беренче чиратта татар милләтен юкка чыгару отышлы. Алар йөз мең итеп безне Беренче бөтендөнья сугышына ташлап та карады, Икенче бөтендөнья сугышына 700 мең итеп куды. Алар безнең балаларны әфган яки чечен сугышларына озатып, мөселманны мөселман куллары белән кырдыртудан да тарсынмый. Инде канлы бәрелешләр юлы белән дә татар халкының санын киметеп, йә аны тез өстенә куеп булмагач, һичьюгы безне кәгазь битләрендә булса да киметә, шулай безнең тез астына суга. Ләкин шул ук вакытта, еллар буе татар милләтенә каршы көрәшкән Мәскәү академигы В.Тишков: «Җанисәптә ким дигәндә 500 мең татар исәпкә алынмаган», – дип белдерү ясый икән, димәк, асыл йөрәкле зыялылар да безнең халыкның талануын раслый...

Уйланырга урын да чиктән ашкан. Татар халкын мондый мәкерле адым көтүен кисәтеп, республика җитәкчелеге ни эшләде? Бөтендөнья татар конгрессы, барча өлкәләрдәге милли-мәдәни автономия җитәкчеләрен җыйнап, нишләп һичьюгы ике-өч тапкыр булса да бертөрле дә уку уздырмады? Мәскәүгә ясак озаткан чагында да, авыл хуҗалыгы буенча уңыш яулаган та, сөтне күп саусак та «Без – лидер!» дип күкрәк сугарга гаять оста бит без. Менә, соңгы җанисәптә без – халык санын югалту буенча Россия күләмендә лидер, ә нишләп бу юлы хөкүмәт башлыклары күкрәк сугарга бер дә ашыкмый соң, ник дәшмиләр?..

Карагруһчы көчләрнең акыра-бакыра ялган сәясәт алып баруын күпләр алдан ук белеп тора иде. Ләкин, ни кызганыч, конгресс үзе уйлап чыгарган стратегия прокламацияләрен таратудан ары татар халкын яклап-саклап калу өчен зур гамәлләр кыла алмады. Бездә яңа сайт, яңа компьютер программасы уйлап табучылар чиктән ашкан, җанисәп вакытында татарлар теркәлү өчен аерым бер ниша ясап кую мөмкин иде ләбаса! «Без – татарныкы!» дип бугаз ярган бер генә театр да җанисәп алдыннан күрше Башкортстан, Удмуртия, Чуашстан, Марий Эл, Комиларга гастроль ясамады. Үзебезнең Язучылар берлеге идарәсенә адым саен Башкортстандагы әдипләрнең дүртәр-бишәр кешелек төркемнәр булып, барча районнар буенча таралуы турында чаң сугып тордык, әмма берлек ни Татарстан, ни Башкортстан буенча шушы җанисәпкә әзерлек буенча сыңар гына төркем дә юлламады. Мәгариф һәм Мәдәният министрлыкларына да барча район һәм күрше республикалар буйлап милләтпәрвәр вәкилләрдән хасил «үгет-нәсихәт» төркемнәре озатырга, татар халкын җанисәптә катнашу һәм аның нечкәлекләрен аңлату буенча аерым чаралар үткәрергә иде, тик берни эшләнмәде. Без халыкны җанисәптән үзебез үк читкә этәрдек һәм ачы, зәһәр җимешен дә үзебез үк татып утырабыз.

Аеруча татар халкының үз теленнән йөз чөерүе бәгырьләрне телә. Ун ел дәвамында тагын бер миллион татар үз телен югалткан. Бүген Татарстанның үзендә дә саф татарча итеп укый-яза белгән милләттәшләр саны 500 меңнән дә артмый. Тагын Башкортстанда гына нәкъ шундый ук сандагы саф татар саклангандыр. Ә Ленинград өлкәсе белән Санкт-Петербургта саф татарча сөйләшә һәм яза алучы бер йөз татар да юк, әле генә үзебез күреп кайттык. Ил буенча татарлар саны 600 меңгә кимегән, дигән тәкрарлауның сафсата икәнен төгәл чамалыйбыз. Ләкин татар бөтен ил буенча «өлкән агай» теленә күчеп бетсә, бөек Тукай, каһарман Җәлил шигырьләре, хөррият һәм бәйсезлек аларның төшләренә дә керә алмаячак. «Кол милләт карагруһчы бакчасындагы тирескә әверелә», дигән яман кисәтү чынлыкта да тормышка ашармыни?!

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Үзенчәлекле утырыш

Швейцариядә16-20 гыйнвар көннәрендә Давос Бөтендөнья икътисад форумының илле өченче утырышы үтте. Дөньяның эшлекле вә сәяси элитасы очрашып сөйләшә торган урын буларак формалаштырылган ошбу форумның темасы быел «Фрагментлаштырылган дөньяда хезмәттәшлек» дип билгеләнгән һәм анда катнашкан делегатларның саны рекордлы 2,7 мең кешегә (шуларның 50 се дәүләт яки хөкүмәт җитәкчеләре, ә 600 дән артыгы дөньякүләм мәгълүм корпорация башлыклары) җиткән. Шул ук вакытта, башка еллардан үзгә буларак, төп уенчылардан дәүләт яки хөкүмәт җитәкчеләре күпләп килмәгән. «Зур җиделек» илләреннән, әйтик, Алмания канцлеры О.Шольц кына катнашкан. Кытай делегациясе дә, үзенең рангы буенча, вице-премьер дәрәҗәсеннән артмаган. Ә Россиядән быел делегатларны чакырып та тормаганнар. Форумның оештыручысы Клаус Шваб утырышны ачканда ясаган чыгышында бүгенге поликризис (энергетика, климат, демография, финанс һ.б. өлкәләрдәге кризислар) чорында аның глобаль җәмгыятьтәге яклар (хөкүмәтләр, бизнес, ватандашлар җәмгыяте һ.б.) өчен очрашу мәйданчыгы булып торуының әһәмияте, ә киләчәкне дә ышанычлы итүдә инде бар якларны да кызыксындырган уртак платформа да булдыру зарурлыгы турында сөйләгән. Утырышның анонсында исә, бүгенге поликризисның дөньядагы каршылыкларны тагы да арттыруы, шуның аша геосәяси ландшафтны да фрагментлаштыруы турында әйтелә. Анда: «Лидерлар халыкның иң кирәкле һәм үтә дә мөһим ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, шул ук вакытта унъеллык ахырына тотрыклырак вә тормышчанрак дөнья өчен нигез дә салып калдырырга тиеш», – диелә. Әйтелгәннәр буенча ниләр майтара алганнар соң әлеге җыенда?

Җавапка күчкәнче, искәртеп үтик, Давос форумының әлеге утырышы аның 50 еллык тарихында, икътисади яктан да, геосәяси планда да гаять катлаулы чорга туры килүе белән үзенчәлекле. Шуны истә тотып булса кирәк, аны оештыручылар, кешелек цивилизациясенең киләчәгеннән төксе төсләрдә тасвирлап,ниндидер шомлы билгесезлеккә дә юл ачты һәм хәттә «Global Risk Report» («Глобаль янаулар турында хисап») дигән доклад та әзерләп чыгарды. Анда дөнья икътисадының бүгенге хәле глобальләштерү чорының ахырын билдергән кискен борылыш мизгеле буларак бәяләнә, алга таба әле экологик вә социаль тетрәнүләр унъеллыгы да фараз ителә. Шулай итеп, моңарчы дөнья тотучылар үткәргән мәҗбүри глобальләштерү сәясәтенә алмашка, «деглобализация» һәм «социаль-икътисади регресс» килә булып чыга. Халыкара аренада да, хезмәттәшлек урынына күпсанлы низаглар килергә, сугышлар исә гадәти нәрсәгә әверелергә, ә икътисади сәясәт инде, геосәяси көндәшләрдән бәйсез рәвештә, үз-үзеңне тәэмин итеп һәм башка дәүләтләрне көчсезләндереп яшәү максатларына хезмәт итүгә күчәргә мөмкин, дип тә фараз кылына. Мондый фаразлар чыгышларда да күзәтелә. Хәтта Кытай вице-премьеры Лю Хе да форумда чит ил инвесторларын үз иленең COVID-19 чорында сүлпәнәйгән икътисадын «кабат эшләтеп җибәрүгә» чакырудан ары китә алмаган. Ә Европа комиссиясе башлыгы Урсула фон дер Ляйен АКШ һәм Кытай үткәрә торган протекционизм сәясәтенең ЕС икътисадына тискәре йогынты ясавы турында белдергән. Давоста Украинага заманча танклар белән ярдәм итү мәсьәләсе дә бик җитди күтәрелгән. Ә дөнья икътисадына чыннан да ыргылышлы йогынты ясардай идеяләр форумда тәкъдим ителмәгән кебек.

Әлбәттә, әлегәчә үзе дә глобальләштерү символы булып саналган Давос форумының бүгенге хәле мәҗбүри глобальләштерү идеясенең тулы банкротлыкка чыгуы турында сөйли. Әмма дөнья тотучылар аның сәбәпләрен поликризис һәм климат үзгәрүе белән генә бәйләп аңлатырга тырыша. Ә инде коронавирус пандемиясе, «сәүдә сугышы», Украинадагы кризис кебек казалар хәлне тагы да катлауландыра торган факторлар гына булып тора, имеш. Әмма әлеге сәбәпләр һәммәсе дә адәми затның рухи деградациясе һәм илаһият кануннары буенча яшәүдән тайпылуы нәтиҗәсе, димәк, икенчел факторлар гына булып чыга. Хәлне тамырдан үзгәртү өчен иң элек беренчел факторны төзәтү лязем. Димәк, адәми зат үз эшчәнлеген һич кичекмәстән абсолют кыйммәтләр системасында бәяләп яши башларга да тиеш була. Моның өчен аңа «мөмкинлекләр тәрәзәсе» агымдагы унъеллык ахырына кадәр бирелә. Экспертлар әйтүенчә, юкса, «кире кайталмау» ноктасы үтелергә мөмкин. Мәсьәләнең дини ягын алганда, рухи борылыш инде илаһият кануннары буенча (киң мәгънәдә) яшәүгә күчүне аңлата. Ислам метафизикасы буенча, димәк, сүз кешеләрнең рухи үсеше (Аллаһка кайтуы) күптөрлелектән бертөрлелеккә кайту шәкелендә барырга, ягъни Аллаһның барлыгын вә берлеген акыл белән (рациональ) тануга кадәр үсеп җитәргә тиешлеге (илаһи глобальләшү) турында бара. Аның иң югары максаты – Җирдә цивилизацион күптөрлелек берлеге урнаштыру аша, гармонияле яшәешкә ирешү.

Фоат УРАЗАЙ.

«Моабит дәфтәрләре» башкалага килде

Мәскәүдәге Татар мәдәни үзәгендә Муса Җәлил истәлегенә концерт булды. Чара М.Җәлил исемендәге «Шагыйрь һәм музыка» II Халыкара музыкаль-шигъри фестиваль кысаларында узды. Фестивальнең сәнгать җитәкчесе –Татьяна Малышева-Җәлил, шагыйрьнең оныгы. Чарада герой шагыйрьнең кызы Чулпан Җәлилова да катнашты.

Концерт кысаларында фойеда легендар «Моабит дәфтәрләре» урнаштырылды. Муса Җәлил музей-фатиры директоры Нәзирә Фәттахова дәфтәрләрнең күчермәләрен Казаннан бер көнгә алып килде.

Фестиваль сәләтле балаларга төрле музыка коралларында уйнарга һәм декламация белән шөгыльләнергә, иң яхшы концерт мәйданчыкларында чыгыш ясарга мөмкинлек бирә. Ул 2022 елның 25 августында С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында М.Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен искә алу көнендә башланды.

Мәскәүдә яшь музыкантлар һәм шигырь укучылар чыгыш ясады. М.Җәлилнең шигырьләре рус, татар телләрендә башкала музыка мәктәпләрендә һәм театр студияләрендә тәрбияләнүчеләр башкаруындагы музыкаль номерлар белән чиратлаштырылып яңгырады. Алар арасында шагыйрьнең оныгы Елизавета Малышева-Җәлил дә катнашты.

Бу көннәрдә концертлар шулай ук Бөгелмә, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллыда уза.

Февраль аенда, герой шагыйрьнең туган көненә ике гала-концерт оештырылачак. Алар Казанда һәм Мәскәүдә узачак. «Зарядье» концерт залындагы чара 25 февральгә билгеләнгән.

1 нче биттә – Казанда узган кар фонарьлары бәйрәменнән бер мизгел. Солтан Исхаков фотосы, «Татар-информ».

Һәр юнәлештә эш мөһим

Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы Бюро утырышы уздырды. Анда Татарстаннан һәм республикадан читтә яшәүче татарларның милли иҗтимагый оешмалары вәкилләре офлайн һәм онлайн форматта катнашты. Утырышны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев алып барды. Җыенның төп темасы халык санын алу нәтиҗәләренә багышланса да, анда милләтебезне борчыган күп кенә мәсьәләләр күтәрелде.

Соңгы елларда дөнья күләмендә глобальләшү көчәйдә. Шуның нәтиҗәсендә Россиядә яшәүче һәр баланың – русча, ә дөньяда барчасының да инглизчә беләсе килә, катнаш никахлар да арта бара. Васил Шәйхразыев, глобализациягә каршы тора алмавыбызны искәртеп, катнаш гаиләләрдә туган балаларга татар рухы сеңдерүгә, туган телләрен өйрәтүгә игътибарны көчәйтергә кирәклеген әйтте. Татарстан Мәдәният министрлыгының гаммәви мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән арадашлык бүлеге мөдире Айрат Фәйзрахманов республикада үз баласын татарча тәрбияләргә тырышкан яшьләр күп булуын искәртеп, Казанның һәр районында татар телле бер милли-мәгариф үзәге булдырырга кирәклеген әйтте. Балаларын татарча тәрбияләргә тырышкан ата-ана Казанның 2 нче гимназиясе турында гына белә. Ерактa торсалар да, ул-кызларын шунда алып барырга телиләр. Балаларын татар бакчасы яки мәктәбенә бирергә ниятләгән ата-аналар башка учреждениедә татарча белем бирелү-бирелмәү турында хәбәрдар түгел. Шуңа күрә Казанның Башкарма комитеты тарафыннан татар телле балалар бакчаларының мониторингы эшләнгән. Кызганыч, ул хакта мәгълүматлы ата-аналар аз. Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла исә татарлар арасында милли мәдәниятне тарату мәсьәләсе – кыен эш, чөнки аларның күбесе тамырларыннан аерылган, дигән фикердә. «Безнең татар – бик аянычлы хәлдә. Яһүдләрдән үрнәк алсак иде. Алар үле тел – ивритны XX гасырда яңарткан халык. Дөнья тарихында бердәнбер юкка чыккан телне яһүдләр дәүләт теле итте», – диде депутат.

Академик Индус Таһиров исә татар халкының саны арта барыр, дигән фикер белдерде. «Тел мәсьәләсендә дин әһелләребез шактый файдалы эшләр башкара. Беренче урында гаилә тора. Гаиләдә татар теле һәм балалары милли рухта тәрбияләү беренче урынга куела икән, алга китеш була», – диде академик.

Милли шура рәисе катнаш никахларны киметү мәсьәләсенә дә кагылды. Шушы нияттән төбәкләрдә, шәһәрләрдә татар яшьләре җыела торган урыннар булдырырга кирәклегенә басым ясады. «Татар яшьләренә очрашып, кавышыр урыннар юк икән, алар үзләренә татар милләтендәге ярны каян тапсын?» – диде ул. Шул ук вакытта яшьләргә күбрәк игътибар бирү соралуын ассызыклап, балалар бакчасына барыпмы, яшьләр белән очрашкандамы, милли орлыклары сала алабыз икән, халкыбызның үсешенә дә өмет булачагын әйтте. А.Фәйзрахманов исә бу уңайдан яше утыздан арткан егет-кызларның гаилә кормау мәсьәләсе дә игътибар үзәгенә алынырга тиешлеген, яшьләрнең танышу клубларын торгызырга кирәклеген белдерде. «Яшьләр комиссиясе булдырыла икән, танышу клублары да эшли башлар иде», – диде ул.

В.Шәйхразыев искәрткәнчә, җанисәп алдыннан гына эшләп алуның нәтиҗәсе юк. Бүген ул стандартлар эшләми. «2030 елда үтәчәк халык санын алу эшенә әзерлекне башлап җибәрергә кирәк», – диде ул.

Шул ук вакытта халкыбыз дөньяда барган технологик яңалыклардан да калышмаска тиеш. В.Шәйхразыевтан да татар телендә GPS юл күрсәткеченең ни өчен булмавы, «Алиса» интерактив колонкасының ни сәбәпле юклыгы белән кызыксыналар икән. «Без, «Яндекс» белән эләмтәгә кереп, татарча «Алиса» ясарга тиеш», – диде Васил Шәйхразыев.

Тарих фәннәре докторы, «Туган җир» журналы баш мөхәррире Дамир Исхаков игътибарны мәктәпләрдә татар тарихын укыту юк дәрәҗәсендә икәнлегенә юнәлтте. «Өстәвенә Россия тарихы дәресләрендә татар халкының тарихы тиешле дәрәҗәдә тәкъдим ителми. Без никадәр тырышсак та, үзгәреш кертеп булмады. Тарих дәресләрендә Алтын Урда чорын үткәндә хәтта «татар» дигән сүз юк, ул «урдалылар»га алмаштырылган. Димәк, балалар рәсми дәреслекләрдә тарихны укыган вакытта системалы рәвештә үз тарихлары буенча белем ала алмый. Тарихыбызга төрле яктан һөҗүм бара, аны ныклап аңлау зарур. Әйтик, Самара өлкәсендә татар халкының төп дошманы Аксак Тимергә һәйкәл куярга тырыштылар. Ярый, тырыша-тырыша, без һөҗүм итүчеләргә каршы тора алдык», – диде тарихчы.

Сөембикә КАШАПОВА.

Юлын белгән арымас

30 гыйнвар көнне Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә музыкант, дирижер, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, профессор, филармониянең һәм Татарстан дәүләт фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе Айдар Фәйзрахмановның туган көненә багышланган зур концерт куела. Халкыбызның яраткан артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, шушы уңайдан узган матбугат очрашуында хәбәр иткәнчә, соңгы 22 ел дәвамында филармониядә җырларны симфоник оркестрга кушылып тәкъдим итү булмаган. «Концерт оркестр катнашында оештырыла. Айдар абый, 28 ел буе опера театрында эшләп, олуг дирижерлар белән хезмәт куйган шәхес. Филармониядә әүвәлгерәк елларда Садри Җиһанов, Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключаров, Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Илгиз Мәҗитов, Илһам Шакиров алып барган эшчәнлек бүген – Айдар абый җилкәсендә. Бу йөкне Айдар Фәйзрахманов бик оста алып бара. Айдар абый фольклор сәнгатен тирәнтен белүче кеше буларак та танылды. Ул татар халык фольклорын матур киемнәр, милли музыка уен кораллары, хәрәкәтләр белән тәкъдим итте», – диде филармония директоры Кадим Нуруллин.

Концертта халкыбыз моңнары Филүс Каһиров, Илгиз Мөхетдинов, Сиринә Зәйнетдинова, Алинә һәм Азат Кәримовлар, Рөстәм Насыйбуллин кебек мәртәбәле җырчылар башкаруында яңгыраячак.

Гомер бәйрәме уңаеннан уздырылган концертына А.Фәйзрахманов бер матур бүләк белән килә: ул иҗатына һәм тормышына багышланган «Юлын

белгән арымас» дигән китап әзерләп чыгарган. «Китабымның һәр бите – гомер агачымның яфраклары. Аларның кайсы җырлый, кайсы сагыш юллый, кайсы арадашчы. Басып тыңлап торам, үткән белән киләчәк арасында. Алга таба өмет баглап, мәңгелеккә кыйбла тотып. Ай-һай, түзәр микән арбам тәгәрмәче?..», – ди хисләргә бирелеп А.Фәйзрахманов. Китап артистның әти-әнисе, туганнары, шул чор турындагы тәмле, гамьле истәлекләр, хатлар, әнисенең көндәлеге, шәхесләребезнең хатирәләре белән үрелеп бара, әмма алар нигездә А.Фәйзрахмановның үзен, иҗатын, тормышын, эшчәнлеген төрле яклап һәм тирәнтен ачып бирә.

Концерт барышында «Юлын белгән арымас» китабы да тәкъдим ителәчәк. Басмадагы вакыйгалар исә фотосурәтләр белән тулыланып, бизәлеп, дәлилләнеп бара. Китапта яраткан җырчыбызның «Татарстан» радиосының «Алтын фонды»на кергән җырлары, телевидениенең «Алтын фонды»ннан «Шигъри тәлгәшләр циклы» һәм шулай ук аның үзе иҗат иткән җырлары да туплап бирелгән. «Юлын белгән арымас» дигән исем исә шагыйрь Газинур Морат әсәреннән алынган. Бу шигъри юл А Файзрахмановның тоткан юнәлеше, киләчәге дә турында кебек.

Басма баштa 1000 данә тираж белән дөнья күргән һәм китапханәләргә һәм татарлар укмашып яшәгән төбәкләргә таратылган. Соңрак тагын өстәмә тираж белән бастырылып, укучылар кулына килеп ирешкән. Беренче концертка килүчеләрне бик матур бүләк тә көтә: артист тамашачыга яңа китабын бүләк итәчәк.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотосы.

Татарча да тиз укып була

Казан федераль университеты студенты Мәликә Хәйрулла татар телендә тиз уку курсы төзегән. Әлегә ул Россиядә бердәнбер. Дүртенче курс студентының «Тиз уку» проекты «КФУ Ел студенты-2022» конкурсының «Иң яхшы студент инициативасы» номинациясендә җиңде.

«Кызганыч, татар телендә тиз уку курслары моңа кадәр юк иде. Рус телендәге методикалар нигезендә тиз укырга өйрәтү, татар телендәге текстларны укыганда, шундый ук нәтиҗәлелек бирмәде яки ике телдә мәгълүматны үзләштерү өчен күп көч таләп итте. Нәкъ менә шуңа күрә мин, туган телемнең үзенчәлекләрен исәпкә алып, татар телендә тиз уку буенча үз курсымны эшләргә булдым», – дип сөйләде студент кыз.

Ул билгеләп үткәнчә, тиз уку өчен тел үзенчәлекләренә туры килгән текстлар төзергә һәм сайларга кирәк. Авторлык курсы өчен эксклюзив материалларны студент татар психолингвистикасы белән танышканнан соң эшләгән.

«Мин татар телендә тиз укуның синтаксик, морфологик, лексик һәм психологик үзенчәлекләрен ачыкладым. Нәкъ менә шушы белемнәр нигезендә тиз уку буенча авторлык методикасын төзергә булдым», – дип аңлатты М.Хәйрулла.

Узган елның җәендә ул үз методикасын сынап карау өчен теләге булган һәркемгә татар телендә алты атналык тиз уку курсын уздырган. Уку нәтиҗәләре күрсәткәнчә, бу чорда укучыларның уку тизлеге уртача 150-250 сүздән 650-1200 сүзгә кадәр арткан, ә мәгълүмат ике-өч тапкыр тизрәк үзләштерелә башлаган.

Читтәге әдипләр читкә тибәрелмәсен

Ижау шәһәренә Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев җитәкчелегендә Идел буе Федераль округы татар иҗтимагый оешмалары җитәкчеләре, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, язучылар Факил Сафин, Рафис Корбан килде.

Кунаклар Г.Тукай исемендәге 6 нчы гимназия, Хөсәен Фәезхан исемендәге лицей, 107 нче «Энҗе» балалар бакчасы, М.Җәлил исемендәге китапханәдә булдылар. Биредә Удмуртиядә гомер итүче татар язучыларының китапларыннан күргәзмә оештырылды һәм иҗат, әдәбият мәсьәләләренә кагылышлы «түгәрәк өстәл» узды. Очрашуга Удмуртия язучылары гына түгел, «Яңарыш» газетасының даими авторлары булган Әгерже районы «Күңел чишмәләре» әдәби түгәрәге әгъзалары да килгән иде.

Хәзерге көндә «Яңарыш» газетасында иҗатка багышланган сәхифәләр атна саен дөнья күрсә дә (проза һәм шигърият), бүген иҗади укучак элекке кебек ялкын бөркеп тормый. Чөнки укучак утын өстәп тору кирәк. Ә өлкән буынга алмашка яшьләр килми. Риза Шәфи, Ибраһим Биектаулы кебек шәхесләр кабызган иҗади ялкын сүнмәсен өчен бар тырышлыгыбызны куйсак та, өметләр акланмый.

Удмуртиядә татар язучыларының әдәби бүлекчәсен җитәкләүче Гөлфия Исхакова да бу хакта үз борчулары белән бүлеште: «2007 елдан бирле Удмуртия Язучылар берлеге әгъзасы булып торсам да, бернинди үзгәреш юк. Язучылар берлеге тарафыннан Удмуртиядә яшәүче бер татар язучысының да китабын чыгарганнары юк. Кайчан мөрәҗәгать итсәң дә, «акча юк» дип җавап кайтаралар. Удмуртия Язучылар берлегеннән, гомумән, безгә игътибар да, кызыксыну да юк. Күпме сорап та, үз идарәләре составына да кертмиләр. Ә җыелышлар узганда, безне ара-тирә чакырсалар да, ул чаралар күпчелек удмурт телендә уза һәм без ни турында сүз баруын да аңламыйбыз. Удмуртия Язучылар берлеге өчен килмешәк булсак, соңгы елларда Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан да безгә игътибар кимеде. 2019 елда ук бастырырга дип, Удмуртия авторларының җыентыгын әзерләгән идек. Татарстан Язучылар берлегенең элекке рәисе Данил Салихов аны бастырырга булышырга вәгъдә иткән иде. Ләкин ул вәгъдә һавада эленеп калды...»

Ркаил Зәйдулла Татарстан Язучылар берлегендәге вәзгыятькә ачыклык кертеп, китап чыгару мәсьәләсендә үзләренең дә мөмкинлекләре чикле булуы турында сөйләп үтте.

Әңгәмәгә Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев, Удмуртиянең Милли сәясәт министры Эдуард Петров та кушылды. Аларны очрашуда күтәрелгән мәсьәләләр белән таныштырганнан соң, Васил Шәйхразыев: «Әгәр сез Удмуртиядә яшәп, бирерә хезмәт итәсез икән, үзегезне килмешәк итеп тоеп яшәргә тиеш түгелсез. «Безнең мәсьәләләрне хәл итәрләр» дип көтеп утырудан файда юк», – дип, китап чыгару һәм башка мәсьәләләрне чишү юлларын күрсәтте. «Әгәр дә хәл ителми икән, әлеге мәсьәләләрне чишүдә үзебездән өлеш кертербез», – диде.

Э.Петров исә мәсьәләне контрольгә алырга вәгъдә итте. «Язучылар берлекләренең, Китап нәшриятларының мөмкинлекләрен чагыштырып, бертөрле таләпләр куюдөрес түгел. Һәр республиканың үз бюджеты. Әмма республикаларда һәр милләтнең мәнфәгате кайгыртылырга тиеш. Бүгенге кебек очрашулар, фикер алышулар, борчыган сорауларны күтәрү – бик мөһим. Күп вакыт халыкны борчыган мәсьәләләр турында җитәкчеләр белми. Татарлар үзләре яшәгән төбәк җитәкчелегенең игътибарын тоеп яшәсәләр, безгә сөенеч булыр иде», – диде Васил Шәйхразыев.

Татарстан кунакларының республикабызга килүе күптән борчыган мәсьәләләрне кабат күтәрергә этәрде. «Түгәрәк өстәл»дә катнашкан һәрбер каләм иясенә дә уйланырга җирлек туды.

Эльмира НИГЪМӘТҖАН.

● 2022 елда Татарстан барлыгы 368 миллион долларлык (якынча 25 триллион сумлык) агросәнәгать продукциясен экспортка чыгарган. Шуның төп өлеше – 255,5 миллион доллары – үсемлек майлары һәм алардан әзерләнгән продукциягә туры килә. 2021 ел белән чагыштырганда, бөртекле культураларны чит илләргә сату 30 процентка, ит һәм сөт ризыкларын экспортка чыгару ике тапкырга арткан. Татарстаннан авыл хуҗалыгы продукциясен Казахстан, Беларусь, Латвия, Германия, Үзбәкстан, Төркия һәм Польша сатып ала.

● Татарстанда былтыр барлыгы 22 авыл хуҗалыгы ярминкәсе үткәрелгән, аларда фермерлар барлыгы 2,1 миллиард сумлык продукция саткан: язын – 500 миллион, көзен – 1,6 миллиард сумлык. 19 марттан 23 апрельгә һәм 10 сентябрьдән 24 декабрьгә кадәр Казанда – 15, Яшел Үзән һәм Чаллыда – икешәр, Түбән Камада өч мәйданчыкта һәм республиканың тагын 26 районында уздырылган ярминкәләрдә барлыгы 18 мең тонна яшелчә (шул исәптән 11 мең тонна бәрәңге), 4 тонна суган, 2,6 мең тонна ит, 360 тонна сөт, 3,5 миллион данә йомырка, 1265 тонна шикәр һәм 882 тонна он сатылган.



Исәнбәт халыкка кайта

«Җыен» фонды тарафыннан «Шәхесләребез» сериясендә күренекле галим, Татарстанның халык язучысы, галим-филолог һәм фольклорчы Нәкый Исәнбәткә багышлап нәшер ителгән фәнни-популяр җыентыкны тәкъдим итү кичәсе үтте. «Син сазыңны уйнадың» дип аталган кичәдә Казанның Тинчурин театры залын тутырып килгән галимнәребез, әдипләребез, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

Кичәнең исеме Нәкый аганың халкыбызда бүгенгә көнгә кадәр популяр булган җыры исеменнән алынган. Дөрестән дә, Нәкый ага Исәнбәт, 93 кә кадәр яшәп, гомеренең һәр сәгатен милләткә хезмәт итүгә багышлап яшәгән шәхес. Ул, унике яшеннән мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар җыя башлап, аннары гомере буе туплаган халык авыз иҗаты әсәрләрен «Татар халык мәкальләре» (өч томда), «Табышмаклар», «Балалар фольклоры» кебек җыентыклар итеп бастырып чыгарган, татар теленең фразеологик байлыгын җыйнап, сүзлек итеп халкыбыз кулына тапшырган. Бер гасырга якын вакыт дәвамында халкыбызны моңландырган «Уракчы кыз», «Бормалы су», «Гармунчы егет», «Син сазыңны уйнадың» кебек җырлары, «Чаң» исемле шигырь җыентыгы, өч дистәдән артык сәхнә әсәре, аеруча «Һиҗрәт», «Культур Шәңгәрәй», «Пикүләй Шәрәфи», «Портфель» сатирик пьесалары, «Хуҗа Насретдин» комедиясе, «Идегәй», «Муса Җәлил» трагедияләре, С.Гыйззәтуллина-Волжскаяга багышланган «Гөлҗамал» драмасы, «Түләк» драматик поэмасы һ.б. проза әсәрләре, көндәлек матбугатта басыла килгән публицистик мәкаләләре, фельетоннары Н.Исәнбәтне талантлы язучы, драматург, шагыйрь итеп таныта. 1984 елда Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәширов көндәлегендә шундый юллар язып куйган: «Нәкый абзыйда булып бераз сөйләшеп утырдык. Фразеологик сүзлекнең икенче томын эшләп утыра. Янәшә куелган ике өстәл кульъяулыгы кадәр кечкенә кәгазьләр белән тулган. Һәр кәгазьдә бер җөмлә, бер гыйбарә, аның төрле вариантлары. Нәкый ага фәнни институтның бер бүлек эшен берүзе башкара. Ә бүлектә 15 кеше эшләргә мөмкин. Хәзер аңа 85 яшь. Ул армас-талмас эшчәнлеген җигеп үзенең сөекле халкына хезмәт итә».

Н.Исәнбәт төрки әдәбият белән танышып барган, дөнья классикларының әсәрләрен татарчага күчергән. А.Пушкинның «Бакчасарай фонтаны», «Полтава» поэмаларын, «Таш кунак» трагедиясен, Мольерның «Тартюф»ын, Шекспирның «Гамлет»ы белән «Король Лир»ын, А.Грибоедовның «Акыллылык бәласе» комедиясен татар теленә тәрҗемә итә. Шекспирны тәрҗемә итү өчен, ул хәтта инглиз телен махсус өйрәнгән, диләр.

«Идегәй» дастаны турында аерым әйтеп китәргә кирәктер. Н.Исәнбәт аны халыктан җыеп, эшкәртү эшен 1930 елларда ук башлый. Ул Бөек Ватан сугышына кадәр үк, 28 чыганакны туплап, «Идегәй» дастанын төзи. Нәкый ага чәчмә дастанны тулысынча тезмә итеп үзгәртә. Шигырь юлларын мәкаль-әйтемнәр белән бизи. Дастан язучы һәм галим эшкәртүендә 1940 елда «Совет әдәбияты» журналының 11-12 саннарында басылып чыга. Н.Исәнбәт «сәнгать реставраторлыгы» юлы белән дастанны иҗади торгызып, аны татарның борынгы гореф-гадәтләре, казанышлары, дәүләт тоту тәртибен, идеалын, омтылышын, холык-фигылен сурәтләнгән тарихи-фәлсәфи роман дәрәҗәсенә җиткерә. Галимнәр искәртүенчә, бер генә халыкта да «Идегәй»нең татарныкыдай камил варианты юк.

Халкыбызга бинигаһә хезмәт калдырган әдип-галим Нәкый ага үзе исән чакта ук әләктән тинтерәгән, мәхкәмәләрдә, аның әсәрләреннән гаеп эзләп үткәрелгән җыелышларда үзенең хаклыгын раслап, күп көч түккән. Егерменче елларда аңа мистик-буржуаз язучысы ярлыгын такканнар, аны татар мәдәниятеннән көлүче дип хурлаганнар, аннары «җидегәнче» дип, «фаш иткәннәр». Ул гаепсез дип табылса да, аңа нахак тагылган атамалар озак еллар буе язучы һәм галим буларак җәелеп эшләргә ирек бирми. Вафатыннан соң да нахак сүзләр тынып тормады. Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев Нәкый Исәнбәт турында: «Юлында нинди киртәләр очраса да, аларны Тукай кебек җимереп барды. Бер чакта да үзенең мәсләгенә хыянәт итмәде. Ул үзе утырткан эш агачына гел су сибеп торды һәм аның агачы төрледән-төрле җимеш бирде. Нәкый ага безнең буынны тәрбияләде. Тиңдәшсез кыюлыгы, милләтне яратуы белән алдагы буыннарны да тәрбияләр», – дип юкка гына язмаган.

Әмма бүгенгә көнгә кадәр Н.Исәнбәтнең барлык әсәр-хезмәтләрен, мәкаләләрен туплап чыгарылган томлыклары да дөнья күргәне юк. Хәтта Татарстан китап нәшриятында 2006 елда нәшер ителгән «Идегәй» дастанында аны кем эшләве турында бер җөмлә дә язылмаган. Нахак сүзләр язучының кызы, таләпчән, гадел, хәтта кырыс холыклы Йолдыз Исәнбәтнең дә җанын бер генә әрнетмәгәндер. Ул вафаты якынлашканын сизеп, әтисенең архивын Казан федераль университет доценты, Аяз Гыйләҗевнең мирасын барлап һәм өйрәнеп, томлыкларын чыгаручы, бер вакыйгага да битараф калмыйча, үз фикерен белдерә торган Миләүшә Хәбетдиновага ышанып тапшыра, архивны барлау эшен башлап җибәрергә булыша.

Галимә, А.Гыйләҗевнең архивы белән танышканда ук, бер документка – Ибраһим Сәләховка язылган хатка тап булган. Анда Н.Исәнбәтне өйрәнергә кирәклеге, нәтиҗәләр ясарга ашыгырга ярамаганлыгы турында язылган була. М.Хәбетдинова да өйрәнергә була. Галимә кичәдә дә: «Мин бер фикер дә әйтмим, документлар сөйли. Тарих бар нәрсәне үз урынына куя! Минем халкым да кара тапларны аклап, кара тарихларга нокта куярга тиеш», – дип белдерде.

Бу уңайдан фойеда кичәгә килүчеләр игътибарына, Н.Исәнбәтнең Тинчурин театры белән хезмәттәшлегенә багышлап, күргәзмә куелган документлар да шактый мәгълүмат бирә иде. Әйтик, анда 28 чыганактан файдаланып язылган «Идегәй»нең астөшермәләре куелган кульъязманы да күрергә мөмкин. М.Хәбетдинова җыентыкта нигездә Нәкый аганың биографик материалларына әһәмият бирелүен искәртте. Китап аша шулай ук Н.Исәнбәтнең татар халкының зур тарихларына карата мөнәсәбәтен белдереп язган материаллары, Йолдыз апаның судта ясаган чыгышы белән дә танышырга мөмкин.

«Җыен» фонды тарафыннан чыгарылган, М.Хәбетдинова төзегән китапта да күп карарларның, документларның, хатларның күчермәләре бирелә. Шулай итеп халыкка мәгълүм булмаган архив материаллары кулланышка кертелә, вакыйгалар ачыклана. Казан федераль университеты профессоры Марсель Бакиров китапның искиткеч зур әһәмияткә ия икәнлеген белдерде. М.Хәбетдинованың ике-өч ел дәвамында Н.Исәнбәт архивын өйрәнүен, иҗади һәм сәяси биографиясен тикшерүен, аларны әйләнешкә кертүен ассызыклады.

М.Бакировка Н.Исәнбәт белән якыннан аралашып яшәргә туры килгән. Нәкый ага аның шигырь үсеше буенча язган кандидатлык диссертациясе яклавында катнашып, фикерен белдереп чыгыш ясаган. Заманында Марсель ага үзе дә аның «Балалар фольклоры» дигән саллы китабына рецензия язган. «Ул – минем фольклор буенча остазым да иде», – диде М.Бакиров.

Татарстанның халык шагыйре, китапның җаваплы мөхәррире Разил Вәлиев, басманы әзерләгәндә, Н.Исәнбәт исемен яңадан ачуы турында әйтте, моның өчен М.Хәбетдиновага рәхмәтен җиткерде. «Мин үземне Нәкый аганы беләм дип йөри идем. М.Хәбетдинова китергән документларны караганнан соң, Н.Исәнбәт мәсьәләсендә үземнең шактый надан икәнлегемне аңладым. Мин аның тормыш юлын өр-яңадан ачтым», – диде ул. Разил әфәнде шулай ук халык иҗатын туплап, сәхнә әсәрләре язып, татар тарихын өйрәнүгә, бигрәк тә Алтын Урда мирасын танытуга зур өлеш керткән Нәкый аганың мирасын, иҗатын, шәхесен мәңгеләштерү буенча республикада зур эшләр алып бару соралуын белдерде. «Һади Такташ, Муса Җәлил, Илһам Шакиров янәшәсендә нишләп Нәкый Исәнбәтнең исемен атамыйбыз? Илһам Шакировның премиясен дә булдырдык. Берәр оешмага Нәкый ага исемен бирдекме?» – диде ул. Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ Н.Исәнбәтнең Тукай мәктәбе белән яшәгән кеше икәнлеген, Һ.Такташ белән дуслыгын, Шәехзада Бабичның аңа багышлап шигырь язуын искә төшерде. «Ул безнең бөек, энциклопедик шәхесебез», – дип белдерде.

Заманында Н.Исәнбәт шәхесләребезгә багышлап М.Җәлил, М.Вахитов, С.Волжская турында әсәрләр иҗат итсә, хәзер инде язучы Рафис Корбан Исәнбәт турында «Җидегәннән төшкән нур» дигән әдәби әсәр язган. Кичәдә катнашучылар бу китапка да югары бәя бирде, авторның шул заманның авырлыгын, Исәнбәтнең катлаулы язмышын ача алуын әйтте. «Р.Корбанның җидегәнчеләр турынгы китабын укып чыктым. Ул Исәнбәт язмышының катлаулылыгын ачкан, аны башкаларга аңлата алган, ул еллардагы вакыйгаларга гадел бәя биргән. Аның әсәрләрендә эчке гаделлек ята», – диде Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Әзһәр Шакиров.

«Нәкый Исәнбәт» җыентыгының редакторы, филология фәннәре кандидаты Фәнзилә Җәүһәрова китапны хәзинә, кырык тартма белән тиңләде. «Кырык тартма дип юкка гына әйтмим, әле бик күп тартмаларга ачкыч табылмаган. Ә бер тартма үзе кырыкка бүленә. Без Миләүшәнең фидакарьлегенә дә, эшләү тизлегенә дә сокланабыз», – диде ул.

Кичәне Тинчурин театры артискасы Резедә Сәләхова алып барды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Күл шайтансыз булмый

Көтелгәнчә, дөньяның 52 иленнән саклану министрлары кергән Контакт төркеменең 20 гыйнварда АКШның Рамштайнда (Алмания) урнашкан авиабазасында үткән чираттагы утырышында Украинага заманча сугыш коралларын күпләп кую мәсьәләсе уңай хәл ителгән. Әмма аны Алманиядә эшләнгән Leopard 2 танклары белән дә тәэмин итү мәсьәләсе (чөнки алар югары сыйфатлы һәм кулланышта да гади) әлегә ачык калган. Берлин Украинага беренче булып үз танклары куелуы белән башта килешмәде. Сәяси экспертлар моның сәбәпләрен төрлечә аңлатты: кемдер хәлне бу илгә хас «гаеплелек синдромы» белән бәйләп караса, икенчеләре аны канцлер О.Шольцның илдәге коалицияне какшатмау теләге белән дә нигезләде. Бары тик бу атнада гына Берлин үзенең партнерлары әйткәнгә күнде.

Узган атнада кайбер шайтани гамәлләр Швециядә дә булды. Алдынгылар рәтендәге бу илдә ультрауң карашлы «Катгый курс» дигән партия лидеры Расмус Палудан атлы кемсә Төркиянең Стокгольмдагы илчелеге каршында демонстратив төстә Корьән китабын яндыру акциясе үткәргән. Сәяси акт Швециянең НАТОга керүенә Төркиянең каршы тавыш бирүенә протест йөзеннән үткәрелгән һәм бу гамәлгә рөхсәтне Швеция хөкүмәте биргән. Премьер-министр Ульф Кристерссон әлеге акцияне законлы, әмма урынсыз акт буларак бәяләгән. Ә Төркия Президенты Рәҗәп Тайип Эрдоган бу җәһәттән кискен канәгатьсезлеген белдергән һәм әлеге акцияне «расачылык һәм заманча кыргыйлык» дип атаган, НАТОга керү мәсьәләсендә Швециягә Төркиядән хәер-фатыйха көтмәскә киңәш иткән. Искәртеп үтик, НАТОда әгъза булып торган 30 илдән бүген Швеция һәм Финляндиянең оешмага әгъза итеп алынуын Төркия һәм Венгрия генә ратификацияләмәгән. Төркия алардан күрд оешмаларын «террорчы» дип тануларын һәм, сыену урыны тапкан андый затлар булса, тотып бирүләрен дә таләп итә. Ә инде «заманча кыргыйлык»ның геосәяси аспектына килгәндә, аны бүгенге хәтәр чорда ислам факторын активлаштыруның бер элементы, дип тә карарга кирәктер.

Атнаның игътибарны җәлеп итәрдәй кайбер башка сәяси вакыйгаларын да санап үтик: быелдан башлап, Дәүләт Думасы депутатлары һәм сенаторларның декларацияләрен игълан итү туктатылачак; 24 февральдән Мәскәү белән дипломатик мөнәсәбәтләрен ышанычлы вәкил дәрәҗәсенә төшерәчәге һәм шуны ук Россиядән дә таләп итүе турында Латвия дә белдерде; Европа Берлегенең дипломатия башлыгы Жозеп Боррель бу Берлекнең Россиягә энергетика бәйлелегеннән арынуы турында әйтте; Европа парламенты Россия буенча махсус трибунал булдырырга чакырган резолюция кабул иткән.

Фоат УРАЗАЙ.

Төп сәбәп – битарафлык

Түбән Новгород татарларының «Туган як» атналык газетасы баш мөхәррире Олег Әндәрҗанов 2020 елгы җанисәпкә карата үз фикерен белдерде. Түбән Новгород татарлары саны, 2010 ел белән чагыштырганда, 40 процентка кимегән. Олег Әндәрҗанов моның төп сәбәбе битарафлык дип саный. Шул хактагы фикерләрен ул «Татар-информ» хәбәрчесенә әйтте.

«2010 елдагы халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре белән чагыштырганда, безнең төбәктә яшәүчеләр 191 482 кешегә кимегән. Моннан 11 ел элек 3 310 597 кеше яшәгән булса, хәзер – 3 119 115», – ди ул.

Шулай итеп, Түбән Новгород өлкәсендә татарлар сан буенча икенче урында тора. «2010 ел белән чагыштырганда, без 40 процентка кимегәнбез. Элек Нижгар татарларының рәсми саны 44 103 булса, хәзер 26 685 кә генә калган. Татарстаннан кала, татарлар санының кимүе Россиянең һәр төбәгендә күзәтелә. Гомумән алганда, 600 мең кешегә азайганбыз. Иң кызыгы, Мәскәүдә дә татарлар саны 45 процентка кимегән», – ди Олег Әндәрҗанов.

Журналист моның сәбәбен битарафлыктан күрә. «Төп сәбәп, бигрәк тә яшьләрдә – битарафлык. Аларда милли үзаң юк. Бездә татар мәктәпләренең күбесе ябылды. Санаулы мәктәптә генә татар теле укытыла. Икенче мөһим сәбәп – яшьләрнең зур шәһәрләргә китеп баруы һәм аларның җанисәп алуда катнашмаулары», – ди ул.

2020 елгы җанисәп вакытында Түбән Новгород өлкәсендә 700 мең кеше үз милләтен күрсәтмәгән. «Аларның күбесен татар дип әйтә алмыйм, әмма алар яшьләр аудиториясеннән булырга тиеш. Безнең яшьләр мисалыннан чыгып, аларның күпчелеге үз милләтенә тупас битарафлыкта тора, дип әйтергә була. Яшьләрдә милли үзаң юк. Бездән бик күп яшьләр Мәскәүгә китеп бара һәм татар телен кирәксенми. Имтиханнарын яхшы бирү өчен, шәһәрдә урнашып калу өчен рус теле кирәк, татар теле белән ерак китеп булмый, дип уйлый алар. Кызганыч, әти-әниләре дә шундый ук фикердә», – ди баш мөхәррир.

Олег Әндәрҗанов татарлар саны кимүнең мөмкин булган тагын бер сәбәбен атады. «Авыллардан гына түгел, яшьләр район үзәкләреннән дә зур шәһәрләргә китеп бара. Иманым камил, аларның күбесе узган җанисәптә катнашмады. Алай гына да түгел, авылларда яшәп калган карт әти-әниләрен дә, пандемиядән саклап, халык санын исәпкә алучыларны өйләренә җибәрмәскә күндерүчеләр булды.

«Һәр татар өчен көрәшергә кирәк. Милләтне, гореф-гадәтләребезне югалтмаска, сакларга тырышырга кирәк», – ди ул.

Татарлар – 15 млн

Ринат Мөхәммәдиев 2020 елгы җанисәп нәтиҗәләренә карата үз фикерен белдерде. Язучы фаразлавынча, Россиядә татарлар саны 15 млн га якын.

«Миңа үз вакытында, халык санын алу процессында совет чорында кайбер оешмалардан вәкил булып билгеләнгән Дмитрий Волкогонов исемле генерал белән аралашырга туры килде. Без аның белән дусларча икәү генә утырган вакытта ул Советлар Союзында күпме татар бар дип сорап куйды. Мин 6-7 млн тирәсе, дидем. Ул бик матур гына серле генә елмаеп, «Кызганыч, бер милләтнең дә санын 6-7 млннан арттырырга ярамый иде шул, ә татарлар 15 млн га якын», – диде. Ләкин бу документ түгел, аны берничек тә исбат итә алмыйм», – диде ул.

Р.Мөхәммәдиев: «Бу фактның дөреслегенә мин ышанам, чөнки Россиянең кайсы гына төбәгенә барып чыкма, татарлар кебек күп таралган башка милләт юк. Россиянең татар, рус халыклары белән бергә нигезләгән ил булуын җитәкчеләр дә кабул итә», – дип аңлатты.

Аның сөйләвенчә, халык санын саклап калу өчен күп нәрсә эшләнмәгән.

«Безнең республика җитәкчелеге Башкортстан җитәкчелеге белән утырып сөйләшә ала иде. Шул ук вакытта Мәскәүдә бу хәлне күреп торган кешеләр, әлеге процессны уен-көлкегә борып калдырган җитәкчеләргә шелтә белдереп алсалар дөрес булыр иде. Үзебездә дә гаеп бар. Үзебезнең халык вәкилләре дә, инде ана телебезне оныткан тәкъдирдә дә, гасырлар буена килгән милли тамырларын да дөрес итеп күрсәтми», – диде язучы.

Әдип фикеренчә, татар кешесе башка милләт вәкиленә өйләнсә дә, кияүгә чыкса да, милләтен шунда ук югалта, кагыйдә буларак балалары да татар булудан туктый. «Кызганыч, без шундый интернациональ, үзебезнең тамырларга битараф бер халык булып чыгабыз», – ди ул.

Ләйсән РӘХМӘТУЛЛИНА.

Балалар аз

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла «2021 елгы җанисәптә татарлар саны кимүнең төп сәбәбе – балалар аз туу, дип белдерде.

«Татарлар гына түгел, руслар да 6 миллионга якын кимегән. Русларның саннары күп икәнен исәпкә алсак, бу – безнең халыкка пропорциональ сан. Аларның да, безнең дә кимүнең төп сәбәбе – балаларның аз тууы. Күбебездә ике бала, аның белән үрчем була алмый, кимендә өчәү кирәк», – ди Ркаил Зәйдулла.

Язучы фикеренчә, бала тудыру мәсьәләсендә татарлар белән башкортлар охшаш. Шуңа күрә татар, мари, чуаш, мордва һәм башка халыклар кимегәндә, башкортларның гына артуы сораулар тудыра.

«Башкортлар саны арту һәм безнең кимү, әлбәттә, сораулар тудыра. Сораулар тудыру гына да түгел, без аның җавабын беләбез инде. Алар безнең исәпкә арткан», – диде Ркаил Зәйдулла.

Җанисәп алдыннан татар язучыларының һәм артистларның Башкортстанда яшәүче татарлар янына очрашуларга баруы, концертлар куюы халык санын алу нәтиҗәләренә йогынты ясамаган, дип саный Ркаил Зәйдулла.

«Үзем Башкортстанның 3-4 районын әйләнеп чыккан идем. Анда зур очрашулар оештыру мөмкинлеге булмады, халык исәбе турында бик сөйләргә кушмадылар. Алай йөрүнең җанисәпкә файдасы юк икәнен белдек. Безнең сәфәрнең максаты – Башкортстанда татар укучысы калганмы, безнең китаплар бармы, җитәрлекме икәнен белеп кайту иде», – ди Ркаил Зәйдулла.

Оештыру начар иде

«Халык санын алу күп төбәкләрдә начар оештырылды», – дип белдерде Тарих институтының фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы Искәндәр Измайлов.

«Ул рәсми рәвештә генә барды дияргә дә була. Паспорт өстәле, хуҗалык кенәгәләре мәгълүматлары нигезендә генә алып барылды. Паспортларда милләтләр күрсәтелмәгән, ә фамилия буенча милләтне ачыклау катлаулы. Шул сәбәпле, татарлар башка милләтләргә дә эләккәндер дип уйлыйм», – ди Измайлов.

Тарихчы әйтүенчә, кайбер төбәкләрдә татарлар саны нык кимүе хәтта демография законнарына каршы килә. «Әлеге эшне оештыручыларга, нәтиҗәләрне ясаучыларга да сораулар бар. Башкортстанда татарлар саны даими рәвештә кимеп бара, 2010 елдагы җанисәп кенә әзме-күпме уңай нәтиҗә бирде. Минемчә, Башкортстанда 200-300 мең татар мәҗбүри рәвештә «башкорт» дип яздырылгандыр. Кимегән татарлар санының бер өлеше шул. Башкортстанда бүген башкортлар санын саклап калу урынына, татарларның үзаңына каршы сугыш бара», – ди галим.

И.Измайлов фикеренчә, Татарстанда җанисәп күбрәк җәмгать оешмалары өстендә. «Башкортстанда администрация, дәүләт бу сәясәткә заказ бирә, махсус программалар чыгара, яхшы финанслар бүлеп бирә. Нәтиҗәсе дә шуннан күренеп тора. Башкортлар саны кимегән очракта да, кискен юкка чыкмый. Татарларның шактый өлешен башкорт дип яздыру бара», – ди тарихчы.

Лилия ЗАҺИДУЛЛИНА.

САБАН КОЙ!

«Тимер тапкан – тилмермәс», –
ди халкым,
Ә көн иткән татар тилмереп.
Бетергәннәр Казан ханлыгында
Тимерлекнең барсын җимереп.

Татар кылычыннан, ук очыннан
Койган җәллад богау-зынҗырлар.
«Заманалар авыр, еллар ябык...» –
Шулчак, ахры, туган бу җырлар.

Богауларын өзеп аттың, халкым,
Кайтты кабат, кайтты Сабантуй!
Ошбу богаулардан койма кылыч,
Ошбу богаулардан сабан кой!

Тапшыр аны Иван Иванычка,
Авыру җаны тәмам терелсен:
«Русское поле!» – диеп
җырлый-җырлый,
Мәскәү тирәсендә җир сөрсен!

Фәрит Габдрәхим 1933 елның 8 гыйнварында Башкортстанның Бүздәк районы Арслан авылында дөньяга килә. Октябрьский нефть техникумын, Башкорт дәүләт университетын тәмамлый. Ул әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе туплап килә. Хезмәт юлын колхозда башлый, төзелештә эшли, мәктәптә укыта. Әдәби иҗатка тартылу аны 1965 елда Туймазы шәһәр газетасы редакциясенә алып килә. Ә 1969 елдан алып 1994 елда лаеклы ялга чыкканчы “Кызыл таң” газетасы редакциясендә әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшли.

Фәрит Габдрәхим 1979 елны СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, дистәдән артык китап авторы.

Без Фәрит аганы олуг гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык һәм яңа иҗат куанычлары телләп калабыз.

Фәрит ГАБДРӘХИМ

«Мирсәетләр, Исхакыйлар – дошман!» –
Ил акырды көн-төн тамак ярып.
Мин лаеклы улың буалмадым:
Такмадылар «дошман» дигән ярлык.
Кичер мине, халкым!

ТӨШТӘГЕ БӘХЕТ

Мин төш күрдем. Һәм беренче тапкыр
Үз-үземне тойдым бәхетле.
Ил түрендә – тәхет! Коткарганнар
Тоткынлыктан татар тәхетен.

Дәһри еллар яшь түгәләр әрнеп,
Әрнетәдер көфер язмышы.
Һәрбер мәхәлләнең мәчете бар,
Җанга шифа – азан тавышы.

Юк табында хәмер. Хәрамлыгын
Яхшы аңлаганнар, күрәсең.
Таһир – Зөһрә туен үткәрәләр,
Таһир – Зоя туен күрмәссең.

Беркайчан да «халык дошманы» дип
Аталмаган Гаяз Исхакый.

Мин төшемдә генә бәхетлемен, Ә өнемдә – чиксез бәхетсез...

* * *

Җан дошманым! Булма куркак:
Түгелсең ич дустым-әшнәм.
Хәлне сорап хәйләләшмә,
Аяк чалып хәрамләшмә.

Качып-посып, арттан түгел,
Күзгә карап, дошманым, бәр!
Көтмәгәндә арттан килеп
Бәрер өчен... дусларым бар.

АДӘМЧӘ ЙӨРИК

Сул белән!
Сул белән!
Сул белән!
В. Маяковский

Димләделәр: «Уң белән!» – дип,
Өндәделәр: «Сул белән!»
Сыңар аякта, титаклап
Киттек тайгак юл белән.

Сабак алдык бугай инде
Озын-озак еллардан:
Таяк була ике башлы,
Ике ярлы – елга да.

Сыңар аякта аксаклап,
Дөнья көлдермик инде:
Уң белән дә, сул белән дә –
Адәмчә йөрик инде.

* * *

Гел сокланып бага идем
Күккә ашкан кыяларга.
Тау башында нурлар чәчеп
Яткан гади пыялага.

Хәзер инде бик еш багам
Кыядагы ояларга,
Тау астында, күләгәдә
Нур чәчмәгән пыялага.

Әллә шулай гомер күзе
Үзгәртәме күңел күзен?!

АВАР ИДЕ

Афәт-давыл
Купты капыл.
Җир-күк тоташ айкала.
Карт каенга чат ябышып,
Кош оясы чайкала.

Авар чиккә җитә каен,
Ә кошчыклар – оядa.
Авар иде... иңендәге
Шул оядан ояла.

БЕЗ ШУНДЫЙЛАР...

Без шундыйлар:
Юл күрсәтүчегә
Иярәбез.
Аннан – үкенәбез:
– Кая алып килдең, мәлгунь?! – дибез
Һәм таш белән бәреп үтерәбез.

Без шундыйлар:
Терсәкләрне тешләп,
И мактыйбыз чөеп күкләргә без:
– Пәйгамбәргә тиң булган... – дип, аңа
Шул ташлардан һәйкәл күтәрәбез.

АРЗАН ХАККА

«Дустың саткан...»
Җиткерделәр
Аңа яман хәбәрне.
Күтәрелеп бәрелмәде,
Ә шулай да гарьләнде.
Гарьләнмәде дус сатканга:
Дус дусны гелән саткан.
Гарьләнде ул дусты аны
Сатканга арзан хакка.

БИК ТӘ ҖИТКӘН...

Хуш исле – җәйнең җилләре,
Яңгырлары – яшенле.
Күз карашларын иркәли
Яшьлек төсе яшеллек.

Мин яраткан яшел төстә –
Күз тимәсен! – күзләрең.
Җәйләреңне күрдем инде,
Күрсәм иде көзләрең.

Әллә инде табигатьнең
Беткән яшел буявы, –
Алсу сары төскә манган
Күпме агач куагын.
Бар дөньяның яшеллеген
Кала алмам яшереп.
Бик тә җиткән,
Саклый алсам
Күзләреңнең яшелен.

ҮЛГӘННӘР ДИП ИСӘПЛИК

Борыннан килгән йоланы
Әле бездә саклыйлар:
Бу дөньядан киткәннәрнең
Яманатын сатмыйлар.

Зиратка алып барганда
Күтәрәләр кадерләп.
Ипләп кенә, бик сак кына
Төшерәләр кабергә.

Искә алалар сагынып
Бары әйбәт якларын.
Мәрхүмнәргә куенында
Исәннәр таш сакларлармы?!

Акыллылар үч алырмы
Дөньядан киткәннәрдән?!
Алар йөгән, авырсынмый,
Салабыз җилкәләргә.

Җәннәттә булсын җаннары! –
Телибез изге теләк.
Җаннарыбыз тетрәнгәндә
Рухлары – ныклы терәк.

Мәрхүмнәргә – зур ихтирам!
Хөрмәт юк – исәннәргә.
Димәк, кирәк исәннәрне
Үлгән дип исәпләргә...

КИЧЕР МИНЕ, ХАЛКЫМ!

«Алтын Урда изгән урысларны.
Вәхши татар – кансыз: аскан-суйган!!!»
Эчтән генә әйттем, эчтән генә:
«Нигә ялганлыйсың, «өлкән туган»?
Кичер мине, халкым!

Туктаталмыйм чиркәү нигезендә
Рәнҗеп яткан кабер ташларының
Сызлануын. Елый алам бары
Диварларга терәп башкаемны.
Кичер мине, халкым!

Күкрәк киергән халкым.«Инкыйраз» дип
Хаталанган Гаяз Исхакый.

Татар белән башкорт арасыннан
Мәскәү сызган чикләр җуелган.
«Идел – Урал» алтын хәреф белән
Тәкъдир тактасына уелган.

...Төшем тәмам. Чынбарлыкка кайттым.
Ә чынбарлык шул ук – тәхетсез.
Мин төшемдә генә бәхетлемен,
Ә өнемдә – чиксез бәхетсез...

КАРТАЙГАН ДИМӘСЕННӘР

И сакаллы сабыйлар, дип, –
Тиргәсә тиргәсеннәр.
Җыр җырлап узыйк урамнан, –
Картайган димәсеннәр.

Күкрәкләрне киерик: безнең
Намуска тимәсеннәр.
Дәрт-дәрманы бар дисеннәр,
Картайган димәсеннәр.

Без йөк күтәргәндә, җәлләп
Ярдәмгә килмәсеннәр.
Яшьләр, әйдә, көнләшсеннәр,
Картайган димәсеннәр.

Хатын-кызлар, безне күргәч,
Тынгылык белмәсеннәр.
Бабай дисәләр дисеннәр,
Картайган димәсеннәр.

КИТӘЛӘР

Китәсем килеп китмимен,
Туган илдән кем туйган?
Халык җыры

Санап беткесез булса да
Юлларында киртәләр,
Чит илләргә, ят җирләргә
Китәләр дә китәләр.

Иске чабата ыргытып
Калыйкмы артларыннан.
Әллә без дә китик микән
Шуларның катларына?

Тормыш – чәчәк

Татарстанда яшәп, милләтпәрвәр кешеләрне очрату хәзер сирәкләште. Әллә туган якларыннан читкә күчеп беттеләрме, тормыш алҗытканмы... 1990 елларда гөр килеп шаулаган милләтчеләребез дә өлкәнәеп, арабыздан китә башлады. Шулай да, Гөлфәния апа Җәләлова белән танышкач, «әле милли җанлы кешеләребез бар икән» дип, сөенеп куйдым.

Аның белән телефон аша гына сөйләшкәнем бар иде. Гөлфәния апа баянчы Рамил Курамшин турындагы язмамны укыган да, мине эзләп шалтыратты. Шуннан соң аның белән һәрчак элемтәдә тордык, ул, иң элек, Рамил абыйның хәле белән кызыксынган иде. Түзә алмыйча, ире Габдуллаҗан абый белән Рамил абый янына барып йөри башлады.

Кайчан сөйләшмә, телефон трубкасыннан Гөлфәния апаның тавышы көр, дәртле яңгырый. Бөтен хәбәрләр белән кызыксына, матбугатны укып бара, ул дөнья белән бер адымда. Әле пенсиягә яңа гына чыккандыр, дип уйлап йөри бирдем. «Бер күрешәсе иде», – дип үзе дә әйткәч, аларның Салмачы бистәсендә урнашкан йортларына юл тоттым.

Барып җиткәч, ни күрим: кирпечтән төзелгән ике катлы коттедж, аның янында машина да тора... Габдуллаҗан абый каршы алырга чыкты. Ә Гөлфәния апа ишегалдында көтеп тора иде. «Синмени инде ул!» – дип, кочаклап та алды. Берничә көн элек шифаханәдә булып кайтканнар: «Габдуллаҗан абыең рульдә үзе иде, гыйнвар башында 90 ын тутырды, үземә быел 87 яшь тула, Аллага шөкер!» – диде күңеле белән һаман яшь Гөлфәния апа.

Мин килгәнгә бераз уңайсызланып калдылар. «Әле оныклар бездә иде, Габдуллаҗан абыең тузан суырткычы белән коверны чистартырга тиеш иде, өлгерми калды бит әле», – диде Гөлфәния апа һәм, күз ачып йомган арада, матур киемнәрен киеп чыкты...

Өйләре бик якты, бар яктан җылылык бөркелә. Эш тышта ялтырап чыккан кояшта да түгел, сәбәп – өйнең торышындадыр ул: әнә, өстәлдә Гөлфәния апа пешергән каз, икмәк, пирог, Габдуллаҗан абый белән җәен тырышып җыйган каен җиләге кайнатмасы тора. Суыткыч ишегендә балалары, оныклары белән төшкән берсеннән-берсе матур фотолар эленгән. Шуларга карап, үзең дә елмаясың, ирексездән, күңелең изри башлый. Барысын да күңел җылысын биреп эшләгәннәр. Гөлфәния апа белән Габдуллаҗан абый ихлас кешеләр булганга шулайдыр ул, дим.

– Иртән намаз укыйм, кичен тәһарәтләр алып, әрвахларга дога кылам, – дип башлап җибәрде сүзен Гөлфәния апа. – Әтинең энисе – әбием бик күпне күргән. Берничә баласы үзе исән чагында вафат булган. Әбинең бер улы Дәүләтша абзый Россия патшасы Николай II нең шәхси сакчысы булган. Аны хатыны революциядән соң сандыкка салып, яшереп алып кайткан. Шунда Дәүләтша абзый үпкәсенә салкын тидереп, бик каты авырып, минем әби белән әнинең кулында вафат булган.

Тагын бер улы – сәүдәгәр Гайфетдин абзый гаиләсе белән 1921 елда Оренбургка чыгып киткән. «Тифтән үләләр», – дигән хәбәр килгән. Соңыннан ачыкланды: Хәмидулла абзыйны балта белән башына бәреп үтергәннәр. Әбинең бердәнбер кызы Бәдрикамал апа 19 яшендә үлә. Әттә сөйли иде: «Таудан төшкәндә, атка бәрмәсен дип, чананы ике кулы белән тотып төшә иде», – дип. Шулкадәр көчле булган! Аулак өйгә барган җирдә бер егет, уйнап башын бәргән. Бәдрикамал апа бер атна эчендә авырып үлә.

Әбинең өч улы гына исән калган иде: Мөхәммәтшәфыйк абзый, Мөхәммәтфатыйх абзый һәм әттәм Латыйп (Гөлфәния апа әтисен яратып шулай атый. – авт.). Әттәмне Бөек Ватан сугышына алдылар. Гармун тартып фронтка китте.

Әттәне озаткан чагында: «Кечкенә генә ил ул, без аны 1-2 айдан җиңеп кайтачакбыз», – дип китте. Мәмәшир авылында әнинең эти-әниләре тора. Мин анда барырга ярата идем. Зөлхәбирә апама бик матур күлмәк алганнарын күрдем. Әттә ул вакытта кибеттә эшли. «Миңа да күлмәк алыгыз», – дидем. «Ай, кызым, бер генә иде ул», – ди эти. Иртүк кибеткә барып карасам, витринада шундый ук күлмәк эленеп тора. Күлмәкне миңа витринадан сатып алып биргәнче елап утырдым. Әттәм алды инде. Шул күлмәкне киеп, әттәмне сугышка озаттым. Сугыш вакытында мин ул күлмәкне башка кимәдем инде – күлмәк кайгысы юк иде.

Әби көн саен икенде – ахшам арасында «эти исән-сау кайтсын» дип, безне тәрәзә янына бастырып, дога кылдыра иде. Аның теләге тормышка ашты, этием сугыштан исән-сау кайтты һәм гомере буе намазда булды.

Эти полкындагы бөтен солдатлар да Татарстаннан булган. Курск шәһәре тирәсендә февральдә көпә-көндез, немецларның ут ату нокталарын билгеләр өчен, полкны кырга керткәннәр. Икенче көнгә тулы полктан 40 кеше генә исән калган. Шул 40 солдатны тагын керткәннәр. Яшь кенә командир, ничә солдат исән калды икән, дип, белешергә әмер биргән. «Беркем дә исән калмаган», – дигән җавапны ишеткәч, яхшырак тикшерергә кушкан. Командирның торып басуы гына булган, үзен да атып үтергәннәр. 5 немец снайперы чиркәү каланчасыннан атып яткан!

Эти бу вакыт сугыш кырында яраланып яткан булган. «Кан киткәнен сизәм. Суларлык булсын дип, карны сыпырып яттым», – дип искә ала иде. Төнлә мәетләрне алып китәргә килгәннәр дә, әттәмнең исән икәнен белеп алганнар. Чаңгыга салып алып киткәннәр, госпитальгә салганнар. «Ике аягыңны да ампутацияләргә», – дип әйткәннәр этигә. Кулының бармаклары юк. Бер хирург: «Аякларын кисмибез, дәвалаячакбыз!» – дигән. Ходайның рәхмәте, этинең аякларын дәвалап, 1943 елда туган ягына кайтарып җибәргәннәр.

Аяклары авыру булды, ләкин икесе дә исән калды. Әтинең исән-сау кайтып җиткәнен белгәч, шатлануларым! – дип хатирәләрен яңартты Гөлфәния апа.

– Мин бик үзсүзле, усал идем, – ди үзе турында Гөлфәния апа. – 37 ел буе төрле мәктәпләрдә физика, астрономия, математика укыттым, урысча белмәгән өчен бик күп авырлыклар кичердем.

Кукмара районындагы Зур Сәрдек мәктәбенең 9 классын тәмамлагач, эти-әни 1952 елда Удмуртиянең Можга шәһәренә күченергә булды. Можганың урыс мәктәбенә укырга кердем. Математика, физикадан – гел «5»леләр инде. «Мәктәпне медаль белән тәмамларга ниятлисезме?» – дип сорады укытучы. Шунда бөтен класс миннән «ха-ха-ха» дип кычкырып көлде. Бер татар малае басты да: «По всем предметам у нее «5»ки. Русский язык ей не поддается пока», – диде. Бөтен фәннәрдән «5», «4»леләр алсам да, рус теленнән мине көзгә калдырмакчылар иде. Рус теленнән диктантны «5»кә язам, иншаны ерып чыгарга көч җитми.

Моңа риза булмыйча, Кукмараның 1 нче мәктәбенә укырга кайтып киттем. Бик яхшы укыдым. Кызганыч, медальсез чыктым. Медаль алыр өчен 9 нчы сыйныфның нәтиҗәләре кирәк иде.

Казан дәүләт финанс-икътисад институтына керергә дип Казанга килдем. Математикадан консультациядә 200 ләп абитуриент җыелган. Бер мәсьәләне исбатлап күрсәтергә куша укытучы. Теләүчеләр юк. Мин кул күтәрдем. Бөтен тактаны тутырып яздым, исбатладым. Укытучы аңлатып күрсәтүемне сорады. Мин исә: «Я по-русски не знаю», – дидем. Татарча булса, татарча гына аңлатып бирер идем, югыйсә.

2 көннән имтихан бирдем. Шул ук укытучы кабул итте. Беренче булып кердем, 7 биремнең барысын эшләп чыктым. «4»ле куйды. Гомуми баллдан укырга керергә 1 баллым җитмәде, мине кандидат итеп алдылар. Кайтып-китеп йөрдем, торыр урыным юк, стипендия юк – вокзалда куна идем. 13 көн йөрдем дә авылга кайтып киттем.

1955 елда Казан дәүләт педагогика институтының физика-математика факультетына укырга кердем, чөнки имтиханнарны татар телендә кабул иттеләр. Математика, физика – «5», химия, немец теле – «4», инша – «3»ле булды. Стипендиясез укырга кердем.

Без гаиләдә 7 бала идек, мин – икенчесе. Акча бирүче юк. 1 курста укыганда, елга портына барып, грузчик булып эшләдем. Авыл баласы каян акча алсын инде? Физикадан Рим Анатольевич дигән яһүд укытучысы керде. Шулхәтле яхшы кеше иде! «Импульс силы, импульс тела» турында сөйләргә кердем. Бу миңа: «Я вам «3» ставлю», – ди. «3»ле куйсагыз, стипендиясез укый алмыйм, авылга кайтып китәм. Биремнәр бирегез», – дим. Бирем яудыра бу миңа! «5»ле куя алмады, чөнки «3»ле куймакчы иде. «4»ле белән чикләнде бу. Ә калган сессияләрдә гел «5»ле генә тезде. Аллага шөкер, стипендиям булды. Шулай итеп педагогика институтын тәмамладым. Тора-бара, шунда русчасын да өйрәндем, – дип дәвам итте Гөлфәния апа.

– 96 нчы мәктәптә эшли башлаган вакыт. Наилә исемле география укытучысы белән татарча сөйләшеп торганда, Аида Петровна дигән завуч: «Это неприлично говорить на языке, которого не знают другие», – диде. Татарча сөйләшүче тыелар иде!

126 нчы мәктәптә эшләгәндә, укытучылар бүлмәсенә кердем. Бер урындыктагы абзый: «Как вас величать?» – ди. «Гөлфәния Латыйповна», – дим. «А как будет по-русски?» – ди. Ул үзен Владимир Дмитриевич дип таныштырды. «А как будет ваше имя на татарском?» – дип сорадым. Исемнәрнең тәрҗемә ителмәвен аңлаттым. Шунда миңа «милләтче» дигән исем тактылар. Аннары ул укытучы белән дуслаштык без.

Һәр милләт укучылары үз телләрендә белем алырга тиеш. Мәсәлән, урысларда «две пятых» диләр. Нәрсә була ул? Татарларда «биштән ике» була. Ягъни бишкә бүләсең, икесен аласың. Физикада «удельная теплоемкость» дигән төшенчә бар. «Удельное княжество» да булган һ.б. Ә бездә – «чагыштырма җылысыешлык». Сунысы белән бүтән матдәләрне чагыштырасың. Бик гади һәм аңлаешлы. «Яңа ел белән» түгел, «Яңа ел белән тәбриклим, котлыйм» диярга кирәк. «С легким паром»ны «җиңел пар белән» дип кенә тәрҗемә итәләр. Бездә «парларыгыз

кенә түгел...



шифалы булсын» диләр. Сөйләмебезне татарлаштырасы килә.

– Гөлфәния апа, укытучы эше бик авыр бит. Чыгырдан чыгарган укучылар да очрап, җенегез сөймәгәннәре булдымы?

– Юк, булмады. Ничек укуларына карамастан, бөтен укучыны ярата идем. Мине «Мирный» бистәсенә 129 нчы мәктәпкә җибәрделәр. Русча да, татарча да укытырга туры килде. Нәфисә Хәйруллина – яраткан укучыларымның берсе. Янымнан китмичә басып тора иде. Камал театрында зур артист булды. Аның белән гел горурландым.

Соңрак Казанның 114 нче һәм 96 нчы мәктәпләрендә укыттым. Кызларым – Наилә белән Зөләйха да миндә укыды. Зөләйхага физика һәм астрономиядән «4»ле куйдым. Физикадан ассистентлар аптырады инде: «Ничек инде үзеңнең кызыңа «4»ле куя алдың? Аннан да яхшырак җавап бирүче булмады», – диләр. Шундый идем инде. Һәрвакыт дөреслек яклы булдым. Үз балаларыма да, башка укучыларга кебек үк, бертигез карадым. Балаларыма «5»ләгә укыгыз» дигән таләп куймадым.

Аннан соң районның, шәһәрнең мәгариф комитетын җитәкләдем. Совет районында 98, 111, 126, 121, 72, 110, 15 һәм 107 мәктәпләрдә татар сыйныфлары бар иде. Ләкин алар өчен мәктәп күләмендә татарча чара үткәрелмәде, алар ятим бала кебек утырды. Ул вакытта Казан мэры Камил Исхаковка гариза биреп, чыгыш ясарга рөхсәт алдым. Үз чыгышымда, шушы мәктәпләрнең берсен генә булса да, татар мәктәбе итеп ясарга тәкъдим иттем.

Россия һәм Татарстан Президентларына хатлар яза торгач, «Балалар үзләрен 20 нче татар гимназиясенә бирергә» дип карар чыкты. Совет районында шул бер татар гимназиясе бар инде, шуннан да арттырып булмады.

Алексей Песошин Совет районын җитәкләгәндә: «Үзегез мәктәп төзегез», – дигән иде. Татарлар үзләренең Татарстанында татар мәктәбен үзләре төзергә тиеш икән.

1990 елларда ачылган татар мәктәпләренең ябылуына бик йөрәгем әрни.

– Татар телендә белем бирә торган татар мәктәбе һәм институты булсын өчен нишләргә кирәк?

– Бердәм дәүләт имтиханын гамәлдән чыгармыйча, татарча укыта алмыйбыз. Татар мәктәпләрен торгызырга кирәк. Брежнев чорындагы кебек, татар мәктәпләрен тәмамлаганнарга татарча имтихан бирдертергә кирәк. Элекке чордагы институтка керү имтиханы системасын кире кайтарырга, татарча имтихан бирү мөмкинлеген булдыру зарур. Татар мәктәбен тәмамлаган, институтка керергә җыенган кешеләргә һәр вузда бюджет урыннары бирсеннәр иде. Татарча укыган балалар өчен нинди дә булса ярдәм булырга тиеш.

Физика һәм математика фәннәре докторы, профессор Сергей Капица БДИ турында: «Ул – мәктәп укучысы белемнәренең объектив картинасын бирә алмый. БДИ бары тик фактларны белүгә яки белмәүгә генә нигезләнгән», – дигән иде. Хәзер менә, татар мәктәбен тәмамлап та, гел «5»кә генә биргән, дип әйткән булалар. Репетиторлар яллап кына бирә ала бит ул БДИны. Мондый система бер илдә дә юк. Америкада мәктәпкә йөри алмаган авыру балалар өчен генә бар.

Башкортстанда Башкорт дәүләт университеты калды, ә Татарстанда юк. Татар дәүләт педагогика университетын булдырырга кирәк. Татарча укыта торган студентларны әзерләр урын юк! Президент каршында татар телен саклау һәм үстерү комиссиясен төзеделәр. Чуашлар – Чуашиядә, марилар – Марида, урыслар үзләренең республикаларында үстерсен. Үстермә, сакла син! Бүген үстергән тел иртәгә аңлашылмаска мөмкин. Телне сакласаң, үзеннән-үзе үсештә булачак ул.

– Соңгы җанисәптә 600 мең татар кимегән, диләр.

– Татарлар кимегән, дип әйтәсем килми. Өйләргә кереп, милләтне сорамады алар. Җанисәп вакытында үзебезнең пунктка бардык. «Татар» дип яздырттык. Төркиядә 5 миллионнан артык Кырым татары бар, Әфганстанда 3 миллион татар бар: инде 8 миллион! Алар барысы да татар. Россия күләмендә әйтмим. Россиядә татар саны кими икән, хакимият гаепле. Росстат биргән мәгълүмат дөрес түгел. Татар исәбенә башкорт белән урысны арттырып йөрделәр.

Бурятлар: «Иркутскида бурятларны мобилизацияләделәр, русларны – юк», – диләр. Якутиядә дә, Татарстанда да шул ук хәл. Алар булмагач, кызларыбыз кемгә кияүгә чыга? Нинди балалар үстерәләр?

Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлеге белән дә канәгать калмадым. Киңәшем шул: чит төбәкләргә барып, татарларга гына кагылган проблеманы да күтәрә белсеннәр иде. Сабантуй белән генә бернишләп булмый. Гадел Кутуй, Муса Җәлил, Һади Такташ туган төбәкләрдән татар язучылары чыгачакмы? Юк, беркайчан да булмаячак. Моның өчен шунда яшәгән татарларны күтәрергә, алар ягында БДИны гамәлдән чыгарырга кирәк. Шул төбәктән килүчеләргә квота булдырырга кирәк.

– «Татарстан Президенты» атамасы үзгәртелүгә ничек карыйсыз?

– «Президент» дигән исем кирәк тә түгел безгә. Төрле оешмаларның президентлары була. «Төрекмәнбашы» диләр. «Татарстанбаш» диярга кирәк.

– Иң якын дустыгыз бармы?

– Илдар һәм Тәфтилә Юзеевләр белән гел аралашып яшәдек. Тәфтилә белән без бер төркемдә укыдык. Илдар минем арттан йөреп карамакчы булды. «Мин сине бик хөрмәт итәм, син – Тәфтиләнең бик якын дусты», – ди. «Шулай булгач, Тәфтиләң янында гына бул», – дидем.

Илдарга инфаркт булган иде. Чехов урамындагы хастаханәгә салдылар. Реанимациягә салгач, кереп караган кеше булмаган...

Илдар киткәннән соң, Тәфтилә яман шеш белән авырды. Янына барып юындыра идем, ризыклар пешереп алып барып ашата идем. Шунда ул миңа: «Гөлфәния, син – мать Тереза», – диде. Китте, бичара. Әле яшәгән дә булыр иде, әкрен генә урамга да чыгып йөри иде. Нурланыш терапиясенә җибәрделәр. Шуннан соң урынныннан тормады...

Әңгәмә барышында Рамил абый Курамшинны да искә алды Гөлфәния апа.

– Синең әңгәмәңне укып, бик борчуга калдык. Номерыңны табып, сиңа шалтыраттык. Ризыклар алып барганыңны ишеткәч, ул ач ята икән анда, дигән фикергә килдем мин. Хәлен белергә дип бардык. Ябыклыгына шаккаттык. Шуннан соң «хастаханәгә салырга кирәк» дигән фикергә килдек, чөнки аяк атларлык, басарлык хәле юк иде.

7 нче хастаханәнең таныш табибе белән сөйләштек. Аксакаллар шурасы рәисе Рәүф Ибраһимов белән күтәреп керттек, күтәреп чыгардык. Ул анда 2 көн булды. Аның трубкасын да алыштырдылар, капельницалар куйган иделәр. Хастаханәгә салганнан соң, дежур кирәк булачак, диделәр. Янында саклап торучы кеше кирәк иде. Хатыны Рузалия ханым калган иде. Ләкин ул саклый алмады. Андагы хирург безгә шалтыратып әйтте: «Рамил абыйны Рузалия апа белән калдырып булмый. Хатыны үзенең кайда икәнен дә белми, – диде. Шуннан соң Рамил абыйны өенә кайтарырга туры килде…

Аның белән хушлашырга дип, Мәрҗани мәчетенә бөтенесе җыелышты, озатырга килделәр. Эш машиналары белән килгәннәр. Эш машиналары белән кайтып киттеләр. Бу хәлгә шаккаттым. Аптырыйм. Менә хәзер Рамил Сөләйман улына дип, аңа багышлап дога кылам, – дип ачынып сөйләде ул.

Габдуллаҗан абый белән Гөлфәния апаның гаилә корып яшәүләренә быел 65 ел була икән. Габдуллаҗан абый – биология фәннәре докторы, профессор. Күп еллар Татарстан Фәннәр академиясе, Ветеринария академиясе, Авыл хуҗалыгы институтында укыткан. Алма кебек 2 кыз үстергәннәр, икесе дә үзләре кебек талантлы.

Кызлары Наилә – архитектура институтын бетергән, рәссам, искитмәле картиналар ясый. Зөләйха – бик матур җырлый, Паркинсон авыруы буенча медицина фәннәре докторы, профессор.

– 2 нче курста укыганда, бәрәңге алырга дип, Югары Ослан районы Бөрек авылына практикага җибәрделәр. Габдуллаҗан абыең Мичурин исемендәге институтны тәмамлап, Татарстанга агроном булып кайткан. Кырда бәрәңге алган мәлебез. Мине чакырды да тегендә-монда бәрәңге калган дип төртеп күрсәтә бу. Ул бәрәңгеләрне үзеннән җыйдырдым аннары (көлә).

Аяк киемем эштән чыкты. Бөтен төркемгә ял көне – мунча көне дип игълан иттем. Аяк киемемне рәтләргә кирәк бит! Кайтып барам, Габдуллаҗан мотоциклын рәтләп маташа. «Кем сезгә ял көне ясарга рөхсәт итте?» – ди бу. «Белмим. Колхоз рәисе урынында түгел. Сорарга кеше юк», – дигән булдым. Аяк киемемне күрсәттем. Габдуллаҗан мине, аяк киемен ремонтлаучы кеше бар дип, мотоциклына утыртып алып китте. Яр буена бардык. Ремонтчы юк икән! Ялганлаган. Кайтыр вакыт җитте. Габдуллаҗанның мотоциклы кабынмады. Тауга менә дә, кире төшә, менә-төшә азапланып бетте. Шунда мин аның сабырлыгына игътибар иттем. Габдуллаҗанга күңелем төште, гашыйк булдым.

Казанга укырга кайткач күрештек, очрашып йөрдек. Габдуллаҗан – Тула өлкәсеннән.

Аерылышырга дигән уй булмады. Балалар – үзебезнеке, тәрбияләргә кирәк. Оныклар дөньяга килде, аларны да карарга кирәк булды. Шөкер, тәрбияләдек. Тормыш ул – чәчәк кебек кенә булмый, авыр вакытларны да күп кичердек. Шундый фикергә килгәнем булды: кияүгә чыгасы икән, үз тиреңдә яшәгән кешегә чык. Эшкә бирелеп үстек инде, җаным. Гел эш, эш, эш булды…

Зилә МӨБӘРӘКШИНА

intertat.tatar

Мәдәни җомга
27 гыйнвар
№3, 2023

САКЧЫ

Дилбәр БУЛАТОВА

Үтереп теш сызлавына уянып китте. Кичке уй иртәнгә ярамый – бүтән кайгы-мәшәкать баштан чыгып очты, тапшырасы сессиянең куркынычы шәүләсе әллә кая юк булды. Теш коргтын дошманыңа күрсәтмәсен! Очлы энәне уртка кадап-кадап алаламыни! Бу авыртудан, бу әрнүдән кая да кереп качарлык түгел. Стенага үрмәлә, суга сикер – аңардан котыла алмыйсың.

Паспорт-полисларын алып, якындагы поликлиникага йөгерде. Андагы теш кабинетында әнисенең таныш табибе эшли, бүген айның җөп көне, димәк, иртәнге сменада аның кизүе. Гомер буе теш белән интеккән әнисе күптән инде танышлык юллаган, аларның гаиләсе тик шушы табибкә генә йөри иде.

Хәерчегә җил каршы – тупсадан атлап керү белән барысы да кире килеп торды. Гадәтенчә, җәһәт кенә узып китәргә уйласа, сакчы туктатты. Ишек төбендәге тар гына аралыкның сул ягына искерәк бер саргылт өстәл куйганнар. Өстәл артында сакчы. Кара төстәге ярымхәрби форма, түшенә, беләгенә сары җеп белән чигеп «ОХРАНА» дип язылган. Сакчыларның бөтенесендә дә була торган хис-тойгысыз чырай, йөгерек күзләр, салкын караш…

Элек сакчылар ил чиген саклаган, төрмә каравыллаган, һич булмаса, төнге ресторанда «төрткәләп чыгаручы» булып эшләгән. Башка урыннарда үткән-сүткәнгә бәйләнеп гомер үткәрергә берәр пенсионер карт йә карчыкны утыртып куялар иде. Хәзер сакчы посты мәктәп, хастаханә, кибет, базар, оешма саен. Һәркайсында типсә тимер өзәрлек ир-ат. Кемне саклыйлар алар? Эчтәгеләрне тыштагылардан-мы, әллә тыштагыларны эчтәгеләрдәнме? Урамнан бусаганы атлап керүгә анда бөтенләй икенче тормыш, икенче тәртипләр хөкем сөрәме әллә? Бусаганың як-ягында бер-берсенә шулай ук дошман халык яшиме? Кергән бер кешегә алар тишәрдәй итеп сөзеп карый – ирексездән, үзеңне нигәдер гаепле итеп тоя башлыйсың. Тәртип бозу уе бөтенләй булмаса да, «кара, мин бу бинада бу начарлыкны кыла алам, теге җинаятьне эшләргә мөмкинмен икән бит!» дигәнрәк уйлар килә башлый. Сиңдә дә үз-үзеңне саклау, шикләнү тойгысы кузгала, ялт-йолт каранып, сакланыбрак атлап китәсең.

Поликлиника сакчысы бигрәк тешләк, каныгучан адәм булып чыкты. Эчкә бахилсыз, ягъни махсус чүәксез үтәргә ярамый икән. Һәм шушы печән кибәне хәтле әзмәвер кергән һәркемгә аяк киеме өстеннән чүәк алып киярргә кирәклеген искәртеп утыра.

Игътибар итми генә үтәргә иде исәбе – сакчы тупас кычкырып туктатты:

– Мин сезгә әйтәм, егеткәй! Бахил алыгыз!

– Соң бу мәҗбүримени?

– Әлбәттә!

Йөз чытып, өстәл кырына килде:

–Минем тешем сызлый, ә сез ниндидер бахил таләп итәсез!

– Тәртип шундый.

– Ничә сум инде?

– Өч сум илле тиен.

Вак акчасы юк иде, ишек төбендә генә касса, ләкин анда да вакларга тапмадылар.

– Күрәсез бит, сдача юк. Болай гына үткәрсәгез?

– Юк, ярамый!

Яңадан урамга чыгарга, якындагы киосктан акча ваклатырга туры килде. Ачуы хәттин ашкан иде – теш сызлавын да онытып, сакчыга теш кайрады.

Тиеннәрне сузды. Сакчы акчага үрелде. Өстәлдәге янчыктан бер пар зәңгәр чүәк алып бирде.

– Ә чек? – диде егет. – Нигә аптырадыгыз? Кагыйдә буенча, товар сатканда, сез сатып алучыга чек бирергә тиешсез. Кая чегыгыз?

Сакчы өстәл тартмасыннан кәгазь бите чыгарды. Исем-фамилияне, түләнгән сумманы язды. Чек алу өчен, ведомостьне кассага алып барырга кирәк икән. Ә анда җиде-сигез кешелек чират җыелган. Кем талон яздырта, кем акча түли. Касса да, регистратура да бирелә, имеш. Кассир хатын, аптырап, бер кәгазьгә, бер егеткә карады. Нигәдер, яшәгән урын, паспорт номеры кирәк булып чыкты. Чираттагылар, канәгатьсезлек белдереп, шаулаштылар.

Ләкин ул нык торырга, бу хәлне ахырынача җиткерергә карар кылды. Хокук белеме өлкәсендә эшләргә җыенган, шунда дүртенче ел укып йөргән кеше буларак, үзенең хаклыгына ышана иде ул.

Җиңүче кыяфәтендә, ведомость сакчының өстәленә ташланды. Тегенең исә моңарда кайгысы юк, ишек төбенә халык җыелган, кемдер тагын ризасызлык белдереп маташа, аларның һәммәсен, ай-вайларына карамый, чүәк итәсе бар иде.

«Бусага сандугачы!» – дип теш агартты егет. – Тапкансың эш! Үгез хәтле гәүдәң белән тупса төбе саклап утырмасаң! Тешсез эби-сәби белән булышып, өч тиенлек бахил сатып, гомер үткәрмәсәң!»

Сакчы белән эләгешү бәланың башы гына булган икән. Яңадан чират торып, әлеге дә баягы касса, ягъни регистратура тәрәзәсенә килеп җиткәч, таныш табибнең бүтән поликлиникага күчкәнен ишетеп, өнсез калды. Нишләргә? Җитмәсә, искәрмәстән теше чәнчеп алды, баскан урыныннан сикереп куйды хәтта. Бу хәлдә шәһәрнең икенче башындагы поликлиниканы ничек эзләп йөрисең?

– Кайсы кабинетка керәсез? Түләүлегәме?

– Ә мондыйга ярамыймыни?

– Ярый, – диде регистратор төксе генә. – Ләкин анда чират.

– Миндә «острая боль»!

– Беләсезме, сезнең алда ничә «острый боль»ле кеше!

– Булса була инде. Көтәрмен. Мин үзем белән акча алмаганмын.

Аңа тиз генә талон язып бирделәр.

Теш табибенә, чынлап та, су буе чират иде. Кискен авыртулы өченче кеше булып чыкты. «Кеше аша үткәрәбез, – дип шаулашты чират. – Монда бер атна алдан килеп языласың, акыллы башлар табылып тора. Әйтерсең, безнең теш сызламый, әйтерсең, без уйнап йөрибез! Япь-яшь, ә үзе нинди әрсез, кара син аны!»

Бер болганмый, су да тынмый – бераздан тынычлык урнашты. Тагын кемдер килде, игътибар аларга күчте.

Теш дәвалау кабинеты төбендә генә була торган, тешкә төшә торган ялыктыргыч көтү башланды. Коридорның сыек сары буяуга буялган дивары, идәндәге шома вак плитәләр, пациентларга битараф кына карап торган ясалма гөлләр күздән үткәрелде, чираттагыларның йөз-чырае, кием-салымы тикшерелде.

Һәркем уйга баткан. Уен түгел сиңа теш авыртуы! Сызламаганда, сиздермәгәндә генә юк кебек ул! Корт төшкәндә генә, аның нинди кирәкле, кадерле нәрсә икәнен төшенәсең. Тешсез тешләп тә, өзеп, чәйнәп, ашап, хәтта сүз әйтеп тә булмый. Әле дә ярый табибләр бар. Борынгылар нишләде микән? Аларның бит бор машиналары да, авыртуны баса торган уколлары да булмаган. Музейга барсаң, ята кеше башлары – тешләре тезелеп тора!

Инде ялыктыргыч чират көтү! Ләкин аның бер файдалы ягы бар. Бердән, син ялгыз түгел, синдәйләр күп – бу үзе күңелгә бер тынычлану бирә. Икенчедән, буй җитмәслек бәхет чыганагыдай тоелган шул ак ишек аша үтү минутларын сагалау – теш кайгысын оныттыра төшә. Бирегә килүнең максаты тешеңне дәвалату түгел, ә күршеләреңнән алдатмыйча, кабинетка үтеп китә алу булып тоела башлый. Әрсезләр исә бихисап. Башларын ия төшеп, карашларын бер ноктага текәп, туктау белмәгән бульдозер сыман керәләр дә китәләр. Танышы монда эшләгәндә, егет үзе дә шулай итә иде. «Карале, читтән күзәткәндә, бу һич тә матур түгел икән», – дип уйлап алды. Ярый әле зур гәүдәле бер пенсионер абзый ишек төбенә барып басты: «Булды, житте, чиратсыз үткәрмибез», – диде, кан сауган күзләрен алартып. Тик аңа карап торалармыни инде. Шәфкать туташы чыгып, кирәк кешене чакырып ала. Ә аңа карышу файдасыз, кереп, аларның кул астына утырачаксың бит.

Сәгать ярым дигәндә, ярымкараңгы коридордан ишекнең аргы ягындагы ак дөньяга үтеп керү бәхете тәтеде.

Яшькелт-зәңгәр халатлы табибә фәрештәнең үзе булып тоелды. Ул – коткаручы, ул – бәгырьгә төшкән сызлану ташын алып атарга сәләтле, ул… ул… Аңа буйсынмый, аның һәр сүзен тыңламый мөмкин түгел.

Әүвәл рентгенга төшәргә кирәк икән. Түләүсез талоннар иртүк бетү сәбәпле, касса белән рентген кабинеты арасында йөргәнче, егетнең урынына кемдер кергән, тагын ярты сәгать үтеп китте.

…Кара бәрхет чалбар, биек үкчәле босоножка кигән, кечкенә буйлы табибә көлемсерәүле карап сорады:

– Авыртуны басарга укол кадыйбызмы?

– Кирәктер инде…

Палачларның җәзалау коралына тиң борау машинасы зырылдады, очлы кораллар, корыч энәләр, игәүләр хәрәкәткә килде. Сәгатьләргә сузылган ничәдер минут, ниһаять, иске трамвай сыман иренеп кенә үтеп китте. Кайгыртучан тавыш яңгырады:

– Нинди пломба куябыз? Әйбәтнеме?

– Әлбәттә!

– Тәәк, икенче категория кариес… өч йөз илле тирәсе…

– Ярар, – дип баш иде. Беләгади, түләүсез пломба берике айдан цемент сыман уалып төшәчәк, ә импорт ямау, уңышлы салынса, бераз чыдый әле ул. – Бәлки, килешербез берәр ничек?

Табибә шыпырт кына шәфкать туташына таба ымлады:

– Аның белән сөйләшерсез…

Авырткан башка тимер таяк – тагын бер теш бозыла башлаган!

– Алдагы атнага килегез, дәваларбыз, – диде уңган, үткен табибә. Бу инде – таныш табибең булды дигән сүз иде.

Алдагы сишәмбегә талон яздырып, гардеробтан кепка белән курткасын алып, көзге янына килде. Сул яңагы шешеп, җилсенеп чыккан. Укол тәэсире кими төште, ахры, утыз ике тешнең утыз ике тамыры кузгалып, берьюлы сыкрый башлагандай тоелды. Бер-ике көн интектерәчәк әле бу!

Авыруның ачуы яман – усаллашып ишек төбендәге сакчыга карады. Ул урынында иде. Һаман бөтенесенә бәйләнеп, чүәк алдыртып утыра.

Егетнең аңа этлек эшлисе килеп китте. Сул ботинкасына уңы белән басып, зәңгәр бахилны ертып җибәрде. Исәбе – чыгып барышлый: «Брак сатасыз!» – дип этләшү. Этләшергә, тек этләшергә!

Шулчак регистратура телефоны шылтырады. Ярымтүгәрәк тәрәзәчектән ялбыр баш үрелде:

– Вадим! Телефонга! Әнисең!

– Сакчыны дәшә икән. Теге, кабалана-кабалана, урындыгын артка шудырды. Куллары белән өстәленә таянып, торып басты. Кинәт йөзе чытылды. Әйтерсең лә ул йөзгә, ул биткә без белән чәнчеп «Әрнү!» дип яздылар. Бер адым атлады, ике, өч… Атлаган саен уң аяк тирән чокырга төшеп-төшеп китте. Елмаюга охшаган ашыгу ишарәсе чагылган иреннәр арасыннан ясалма тешләре күренеп китте. Егет аптырап идәнгә карады. Юк, бернинди чокыр юк. Тип-тигез, чип-чиста, шоп-шома! Көзгедәй өслегенә тар тәрәзәләрдәге жалюзилар аша буй-буй нур тасмалары гына сузылган.

– Армиядән гарипләнеп кайткан ул, – диде регистратор хатын, күзлеген төзәткәләп. – Чак исән калган.

Сакчы белән күзгә-күз очрашмас өчен, егеткәй, карашын яшереп, башын түбән иде. Күзе аягындагы чүәкләргә төште. Бая үзе ерткан, атлаган саен сәламә калдыклары булып җилфердәгән чүәкләрне берничек тә яшерү мөмкин түгел иде.

(Ахыры. Башы 1, 2 нче саннарда).

Азнакай авылы

Күренгәнчә, Елачичлар кебек, Микулиннар да төбәк тарихында билгеле роль уйный. Микулино авылының барлыкка килүе дә фәкать аларның эшчәнлеге белән бәйле. XVIII гасыр ахырында авылга бертуган Парфир һәм Павел Микулиннар нигез сала. Алар мондагы җирләрне 1788 елны полковник Н.Л. Сумароковтан 2500 сумга сатып ала. 1859 елда Микулинода 39 хуҗалыкта 299 кеше яши, чиркәү һәм завод була.

Азнакайның 1900 елгы тормышын тасвирлауны дәвам итик. Авылда ике көтүче булган. Фәхретдин Афзалетдинов (35 яшь) – атлар, Идиятулла Фәйзуллин (30 яшь) сыер һәм сарыклар көткән. Көтү сезоны алты ай ярым-җиде айга сузылган.

Авылда тегермәнче булып эшләүчеләр дә бар. Мәсәлән, Газизулла Мөхәммәдиев (50 яшь) ел буена күрше Уразай авылы тегермәнендә эшләгән, анда ашлык салып торган.

Умартачылык турында сүз булса да, бу шөгыльгә бәйле кешеләрнең барысы да әйтелмәде. Алдарак телгә алынмаганнарын атап үтик. Госман Әхмәтҗанов – 35, Шәрәфетдин Әхмәтҗанов– 15, Гыйззәтулла Габбәсов – 15, Фазулла Вәлиев – 10, Мөхәммәди Хәмидуллин – 7, Хәйрулла Кәлимуллин – 6, Габдерәхим Ибраһимов 3 баш умарта тота.

Тормыш бит, төрле бәла-казалары да булып тора. Иң еш кабатланып торганы – янгын чыгу. Статистик мәгълүматлар 1905-1912 еллар эчендә Азнакайда 19 янгын чыгу очрагын терки. Шуның нәтиҗәсендә 197 хуҗалыкка зур зыян килгән, күпләре йортсыз калган. Мәҗбүри страхование буенча взнос түләп барганлыктан, килгән зыянны каплау өчен бу хуҗалыкларга барлыгы 4414,13 сум акча бүленә.

1905-1907 еллардагы аграр хәрәкәт төбәкне читләтеп үтми. Бөгелмә өязендә аз җирле крестьяннар алпавытларның җирләрен, урманнарын бүлү турында ешрак сүз кузгата башлый. Мәсәлән, Бәйрәкәдә, халык хәрәкәтен бастыру өчен хөкүмәт гаскәр куллана. Ике арада бәрелешләр була, кан коела.

Азнакай тирәсендәге авылларда крестьяннарның ничек җир даулауларын бер документ ачык чагылдыра. Ул «Представление Самарского губернатора 9 апреля 1907 г. министру внутренних дел» дип атала. Анда шундый юллар бар: «[...] Засим бугульминский уездный исправник доложил мне, что 28-го марта в деревне Тетвель, Микулинской волости, Бугульминского уезда состоялся тайный неразрешенный сход жителей соседних селений: Чемодуровки, Алферовки, Оводовки, Старой Зверевой, Тимяшевой, Монашкиной, Ивановки, Владимировки, Александровки, Микулина, Малой и Большой Федоровок, Дмитриевки, Бирючевки, Старой Сумароковой, Фаевского товарищества и Окружновки, на котором обсуждались аграрный и рабочий вопросы, при чем постановлено: если государственная дума не удовлетворит землей населения весной текущего года, то все население должно самовольно пахать владельческие земли, экономии разграбить, а рабочих перед началом полевых работ снять, и тем лишить владельцев возможности обрабатывать свои поля. Есть указания, что сход этот состоялся по инициативе члена государственной думы от Бугульминского уезда Атласова, который в письме своем советует составлять приговоры, излагая в них всю надобность в земле и другие нужды, и присылать эти приговоры ему. Кому было послано Атласовым письмо и какого именно содержания пока не выяснено. Дознание по сему делу производится» (Аграрное движение в 1905-1907 гг. Том 1).

Чыннан да, авыллар зурайган саен, җир җитмәүчәнлек торган саен үзен сиздерә. Алпавытлардан һәм казнадан җир сатып алу бик азларның гына көченнән килгән. Хөкүмәт крестьяннарның хәлен яхшырту турында уйлап та карамый. Менә шундый шартларда аграр хәрәкәт башлануга җирлек туа.

Документта Һади Атласи фамилиясе телгә алыну очраклы түгел. Дәүләт думасына халык тарафыннан сайланган депутат буларак, ул аграр хәрәкәттән читтә кала алмый. Әлеге вакыйга (сход) Атласиның күпкырлы эшчәнлегенең бер ягын һәм, гомумән, Азнакай төбәгендәге авылларга аның йогынтысы зур булуын күрсәтә.

1910 елгы мәгълүматлар буенча, Азнакай 438 хуҗалыктан тора, анда 1024 ир-ат һәм 1017 хатын-кыз яши. Монда земство стансасы, волость идарәсе, хәрби хезмәткә чакыру пункты, урядник фатиры урнашкан. 2 мәчет, мәктәп, 5 су тегермәне эшли. Ул элеккечә Самара губернасының Бөгелмә өязенә керә.

1891, 1892 һәм 1897-1898 еллар кебек, 1911 елда авыл халкы өчен гаять авыр була. Җәй коры килү сәбәпле, игеннәр башакка бөреләнмичә көя. Нәтиҗәдә, игенченең яңа уңышка өмете сүрелә, авыр, ач айлар башлана.

Иген уңмау Самара губернасының бөтен территориясен диярлек чолгап ала. Бу бәхетсезлек белән көрәшү өчен хөкүмәт шактый сумма акча бүлә, ачка интегүче халыкка төрле ярдәм оештыра. Әмма ул ярдәм ихтыяҗның бер өлешен генә канәгатьләндерерлек булганлыктан, аерым кешеләрдән һәм җәмәгать оешмаларыннан кергән иганә исәбенә ашханәләр ачып, бушлай туклану оештырырга кирәк була. Шуны күздә тотып, Самара губернасында «Шәхси оешмаларның берләштерелгән комитеты» оештырыла. 1912 елның гыйнварында беренче утырышы булып уза. Анда, комитетка ярдәмчел орган буларак, махсус комиссия төзелә. Комитет карары буенча, ачлыктан интегүче халыкка фәкать азык-төлек белән ярдәм итү күздә тотыла. Ашханәләр ачып, бушлай тукланулар оештыру, андый мөмкинчелек булмаган очракта, он, тары ярмасы һәм май паеклары әзерләү карала.

Ашханәләр ачу өчен иң башта вәкил яисә контролер урынга барып, халыкның күпме дәрәҗәдә ярдәмгә мохтаҗ икәнлеген ачыклаган. Аннан соң мохтаҗларның гаилә һәм матди хәле күрсәтелгән исемлек төзелгән. Ул комиссиядә каралып, аның бәяләмәсе белән комитетка тапшырылган.

Баштарак, иген уңмау Бөгелмә өязенә, башкалар белән чагыштырганда, азрак зарар китергән дип уйлыйлар. Өяздә зәңгелә авыруы башланган дигән хәбәрләр Самарага барып ирешкәч кенә, апрель ахырында ярдәм оештырыла.

Азнакай ягындагы авылларга ярдәм оештыру гомум земство оешмасына йөкләнә. Аның җитәкчесе С.А. Елачич була.

Азнакай волостеның Азнакай, Әгерже һәм Балтач авылларында ашханәләр ачыла. Волостька вәкил (Бирюзов), ашханәләр мөдирләре (Рязанова, Майкова һәм Горшенина) билгеләнә. Азнакайда 150 кеше – 31, Әгерҗедә 150 кеше – 26, Балтачта 150 кеше 37 көн дәвамында бушлай ашханәләрдә туклана. Азнакайда – 4650, Әгерҗедә – 3900, Балтачта 3550 порция өләшенә. Бер порция яисә паекның бәясе 3,5-4,1 тиен торган.

Азнакайда аерым кешеләрнең сәүдә эшчәнлеге хакында алдарак шактый әйтелде. Чираттагы мәгълүмат «Вся Россия» исемле белешмә әдәбияттан. Якуп Ильясов һәм Фәхретдин Исмәгыйловлар 1911-1912 елларда Азнакайда икмәк сәүдәсе белән шөгыльләнгән. Әгерҗедән Гыймадетдин Галиуллин бакалея һәм мануфактура товарлары белән сәүдә иткән.

1913 елда Азнакай һәм төбәктәге башка авыл кешеләрендә зур кызыксыну уяткан вакыйга була. «Самара крестьян хуҗалыгын яхшырту җәмгыяте» Туйкә кредит ширкәте аркылы Туйкә, Уразай, Әсәй һәм Балтач авыллары хуҗалыкларына мал чөгендере орлыклары өләшеп, аны игүне оештыра. Көз көне бу авылларда, төбәктә беренче тапкыр, чөгендер уңышы җыеп алына.

Чөгендерне барлыгы 44 хуҗалык чәчә. Аларның 13 ендә, шытымнар зарарлану сәбәпле, уңыш булмый. Калган хуҗалыклар югары уңыш ала. Уразайдан Исламгали Солтангалиевта - иң югары уңыш. Ул 0,5 кадак (Россиядә фунт (кадак, гөрәнкә) – 409,5 граммга тигез булган үлчәү берәмлеге) орлык чәчеп, 40 пот чөгендер ала. Җир мәйданы хакында мәгълүмат юк. Орлык куе итеп чәчелгәнне искә алганда, чәчүлек мәйданы зур булмагандыр. Туйкәдән Миңлегали Тәхаутдинов – 24, Балтачтан Исламголов – 16, Заһидулла Яруллин – 13, Әхмәтҗан Мөхәммәтҗанов – 10, Гыймаделислам Фәхрелисламов 10 пот чөгендер үстерә.

Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Азнакайда тагын бер мәчет салына. Аңа рөхсәт 1910 елның 15 июлендә бирелә. 1913 елда өченче мәхәлләгә хатыйплыкка – Фәтхелбәян Насретдин улы Ярмәков, мөәзинлеккә Әгъләметдин Шиһабетдинов раслана.

Сугыш авылның социаль-икътисади үсешенә гаять тискәре йогынты ясый. Бу 1916 елда үткәрелгән авыл хуҗалыклары исәбен алу материалларыннан күренә. Азнакайда 477 хуҗалык, 989 ир-ат һәм 1261 хатын-кыз теркәлә. Сугыш тәмамланмаган, шуңа күрә ир-атлар хатын-кызларга караганда күпкә аз.

Сугыш елларында Азнакай волостенда качаклар күренә башлый. Алар Азнакай (18 кеше), Уразай (15), Балтач (4), Әгерже (3), Сәпәй (2) һәм Әсәй (3) авылларына килеп утыра. Азнакайда качакларның барысы да хатын-кызлар була.

Авыр сугыш елларында да авыл халкы күп мал-туар тота. Азнакайда барлыгы 876 ат (шул исәптән 711 эш аты), 927 мөгезле эре терлек һәм башка вак-төяк маллар, 3547 сарык һәм 875 кәҗә теркәлә.

Билгеле, хуҗалыкларга карап мал-туар саны аерылган. Бигрәк тә гаилә башлыклары сугышка киткән хуҗалыкларга авыр була. Аларның мал-туарлары һәм чәчүлекләре азая.

Әлеге авыл хуҗалыгы исәбен алу документларында типтәр һәм башкорт сословиеләрендәге азнакайлыларның милләте татар дип язылган. Патша хөкүмәте чорында бик сирәк очракта гына милләт күрсәтелә, шуңа күрә бу чыганак аерым игътибарга лаек.

● Азнакай буенча 1916 елгы документ фрагменты. Сословиесе – типтәр, милләте татар дип язылган.

Совет чоры – Азнакайның үсешендә аерым, зур этап. 1918 ел ахырында авыл комиссары вазыйфасын Зарип Садыйков башкара. Волость башкарма комитеты рәисе итеп Газизулла Вәлиуллин сайлана. Закирҗан Габдуллаҗанов, Хәсән Кәримов, Миңлегали Вәлиев монда әгъза булып тора.

1920 елда Азнакайда 490 хуҗалыкта 2225 кеше яши. 1921 елгы ачлыктан күп гаиләләр кырыла, авыл кечерәеп кала. 1926 елда нибары 361 хуҗалык, 1578 кеше исәпкә алына. Авыл элеккечә волость үзәге булып тора, тик бу юлы – Бөгелмә кантонында.

Бөгелмә кантоны бетерелеп, бер ел вакыт үткәч, 1931 елның 30 октябрендә Азнакай районы оештырыла. Тымытык районы бетерелгәч, аның территориясе дә Азнакай районына кушыла. 30-40 нчы еллар авылны тагын сынаулар, фаҗигаләр алдына куя. Репрессияләр, сугыш вакытында авыл йөзләрчә асыл ир-егетләрен югалта. Дөньялар тынычлана төшкәч, авылның йөзе үзгәрә, матур йортлар төзелә, кешеләрнең күңеле күрә.

1956 елдан Азнакай – шәһәр тибындагы поселок. Төбәктә нефть чыгара башлау поселокның үсешен тизләтә. Кыска вакыт эчендә йөзләрчә йортлар, дистәләгән социаль-көнкүреш объектлары төзелә. 1987 елда Азнакай шәһәр статусын ала. 1997 елда монда 36,6 мең кеше яши. 1991 елның 2 декабрендә җөмһүриятебезнең Мәдәният министрлыгы приказы белән Азнакай төбәкне өйрәнү музеена нигез салына.

Азнакай шәһәре – төбәкнең сәнәгать үзәге дә. Монда «Азнакайнефть» нефтьгаз чыгару берләшмәсе идарәсе урнашкан, «Нефть машиналары» тәҗрибә заводы, УАЗ автомобильләрен ремонтлау заводы, май җитештерү, ипи пешерү заводлары, тегү фабрикасы эшли.

Соңгы дистә ел эчендә район игенчелек һәм терлекчелек продуктларын, промышленность товарларын җитештерүне сизелерлек арттырды. Нефтьчеләрнең дә эшләре көйле бара, «кара алтын» чыгаруда зур уңышларга ирештеләр.

Таһир КӘРИМОВ,
тарих фәннәре кандидаты.

ПЕТЕРБУРГКА

● Тукай һәйкәле янында Р.Галиуллин һәм сынчы Ә.Зыякаев.

Илнең төньяк башкаласы яки революцияләр казаны булган Санкт-Петербург каласына 20 ел элек үк барганым бар иде. Ул вакытта Чаллы каласының мәдәният хезмәткәре булып, ике ел рәттән Петербург Сабан туенда катнашу өчен бардык һәм, кунакханәләрендә төн кунып чыккан хөрмәттән, йөгерә-йөгерә генә, төньяк Пальмираның Смольный сараен, Нева проспекты белән кисешкән Грибоедов, Фонтанка каналларын, кенәз Йосыповлар сараен, Җәйге бакчаны, андагы Петр патша йортын, «Аврора» крейсерын һәм тагын 3-4 кенә истәлекле урынына күз йөгертергә өлгерә идек тә, аерылып калудан куркып, янә ерак юлга чыгачак автобусларыбызга кереп чума идек. Шуңа күрә «Петербургны күргән бар ла ул!» – дип күкрәк сугарга кыймыйча гына, тыйнак гомер иттек.

● Без Җәлил һәйкәле каршында.

Ниһаять, менә яңа елга аяк басуга ук, «Татмедиа» берләшмәсенең генераль директоры Шамил Садыйков кул астында, бер төркем әдип һәм журналист хыялда яшәгән Петербург каласына сәяхәткә киттек. 2021 елда үткәрелгән җанисәп нәтиҗәләре үзәкләрне өзә: Рәсәй буенча татарларның саны – 600 меңгә, Петербургта – 35, Нижгарда – 40, Мәскәүдә хәтта 45 процентка кимегән, ди, имеш; асылда да шулаймы, әллә соңгы еллар сәясәтенә хас булганча, җанисәпкә дә икейөзлелек вә хәрам катнашканмы? Һәм, гомумән, төньяк башкала татарлары ничегрәк көн күрә дә, алар арасында бердәмлек вә аркадашлык бармы?

Безне Татарстанның Петербург каласындагы даими вәкиле Ренат Вәлиуллин һәм аның урынбасарлары каршы алды. Сүз дә юк: иң беренче эш итеп, милләтебезнең йөзек кашлары булган Г.Тукай белән М.Җәлил хөрмәтенә әлеге калада куелган һәйкәлләр янына барып баш идек һәм чәчәкләр куеп кайттык. Шушы калада гомер итүче сәнгать остасы Әхнәф Зыякаев бөекләребез сыннарына бар күңел җылысын салган, шуңа күрә алар Казандагы һәйкәлләргә караганда да сөйкемлерәк, зәвыклырак һәм реальрәк сыман. Соңыннан атаклы «Җәлил укулары»на әверелгән тантаналар да иң беренче булып Петербургта канат ярган икән...

Татарстан вәкиллеге бинасында Петербургның гына түгел, ә якын-тирәдәге Тосно, Красное Село, Гатчина, Луга, Кронштадт калаларының татар мәдәни үзәге җитәкчеләре белән танышу башланды. Калада морзалар мәҗлесе дә актив эшли икән, аның җитәкчесе, тумышы белән Туймазыдан булган Сәлим Хәсәновның иң актив морзаларга Николай патша нәселдәшләре исеменнән орденнар тапшыруын да тамаша кылып алдык. Соңыннан танышканда тәхеткә тугры морзаларның Пенза, Нижгар якларыннан килеп урнашкан нәселдәшләр булуын ачыкладык. Әле алдагы көннәрдә дә «борынгы» заманда ук, иң беренче булып килгән татарларның дәвамчыларын эзләп гаҗиз булдык, алар табылмады.

Кызганыч, ә тәүге татар эшчеләре Петербург каласы нигезләнгән 1703 елда ук патша тәхете алдында бил бөгә һәм төзелешләрдә тир түгә башлаган, югыйсә. Шул елның май аенда ук тирә-юне тоташ сазлыклардан хасил Нева ярында Петропавел крепосте астына беренче ташларны сала башлауга ук, Петр патша фәрманы буенча Казан провинциясеннән беренче биш мең татар ире куып китерелгән, алар үзләренә яшәү өчен беренче айларда ук 17 агач йорт һәм «төрек» мунчасы төзеп куярга да өлгергән. 1704 елда – тагын биш мең, 1705 елда янә биш мең татар куып китерелгән, аларның бер өлеше Кронштадт крепостен төзүгә җәлеп ителгән. Тәүге ике партия турында мәгълүмат сакланмаган, ә 1705 елда килгәннәр арасыннан фәкать 800 ир генә, әле анда да ярымгарип көе туган якларына әйләнеп кайта алган. Димәк, «Питер каласы татар сөякләре өстендә калыккан», дип язган тарихчылар сүзендә бер хата да юк икән. Моны 1705 елларда ук Татар бистәсе һәм Татар базары барлыкка килү дә раслый, бүгенгә кадәр Питер үзәгендә «Татар тыкрыгы» дип аталган аерым урам да бар. Петербургтагы Татар бистәсендә гомер итүчеләр Петр патша 1719 елда үткәрә башлаган беренче җанисәп кәгазьләрендә дә теркәлеп калган. 1722 елдан соң татарларны Балтыйк диңгезе ярында Рогервик (хәзер Эстониядәге Палдиски) гаванен төзүгә дә җәлеп иткәннәр...

Ә үз исемендәге каланы төзү өчен Петр патша татар крестьяннарын куып китерү белән генә дә туктамаган әле. Ул 1704 елның җәендә Казан белән Уфа провинцияләренә халыктан ясакны акыртып талау өчен Дохов һәм Жихарев атлы ике эмиссарын юллаган, ә теге котырган этләр татар белән башкорт милләте өстенә 72 төрле яңа ясак салган: «Бәке өчен – салым, көтүдә йөргән сарык өчен – салым, әгәр аны суйсаң, тиресе өчен дә – салым, кое, мунча, аның мич торбасы, тәрәзәләр, дуга, мулла, никах, чүмәлә... – һәммәсе өчен салым. Ул гына да түгел, соры күзле булсаң – 6 тиен, зәңгәр яисә кара күзле булсаң – 8 тиен салым!» Бабайлар безнең

● Иҗат йортында Петербургта яшәүче татар рәссамнары һәм журналистлары белән очрашу истәлеге.

● Эрмитажда патшаларның Герб залы.

Сәяхәт

● Без Кызыл авылда Г.Алимов төзегән милли үзәк янында.

дәрәҗәдә кол вә күндәм булмаган, сәнәк-чалгыларга ябышканнар. 1711 елга кадәр дәвам иткән әлеге Күчем-Алдар фетнәсе чорында патша карательләре 12 меңнән артык татар ирен кырган. Ә 1722 елда, инде Кавказны яулау өчен поход башлагач, Петр патша Казан губернасыннан янә 30 мең җайдакны үз гаскәре алдыннан куалап алып киткән. Шул 1722 елда Кырым татары Кантемир һәм Казан татары Котлыгмөхәммәт Тәфкилев ярдәме белән беренче татар прокламацияләре бастырып та Петр патша безнең бабаларның күңелен күргән әле. Әмма Рәсәй хакына Баку белән Дербент калаларын яулаганда ничәмә-ничә мең татар кырылгандыр, моны белүче юк...

Һәм бу бердәнбер корбаннар да түгел. Ленинград каласын блокададан азат итү өчен яуларда бер Татарстаннан гына да 20 меңгә якын татар солдаты мәңгелеккә ятып калган. Ходайның рәхмәте, Татарстан вәкиллеге һәм җирле тарихчылар тырышлыгы белән Җиңүнең 75 еллык бәйрәменә Татарстан җиреннән китеп шушында һәлак булган якташларыбызның исемнәрен аерым китап итеп чыгарганнар. Алар арасында туган авылым Байсардан гына да 11 шәһит яугир, берсе – әткәйнең бертуган абыйсы Мәгъдәнур абзыкаем...

Ленинград каласын хәрабәләрдән күтәргән чагында Татарстан да читтә калмаган, ул дүрт эшелон яшь төзүчеләр озаткан. Илленче елларда Ленинград – ябык шәһәр, дип игълан ителгәч, мөгаен, ул төзүчеләрнең бер өлешен кайтарып җибәргәннәрдер. Ләкин яшьлек – тыю-кууларга бирешә белми торган заман, әйтик, яртысының гаиләләр корып, шушында яшәп калуы да мөмкин. Болай санавымның сәбәбе шул: Ленинградта әле Бөек Ватан сугышы башланганчы ук гади матрослар гына түгел, ә беренче һәм икенче рангтагы капитаннар да гомер иткән инде. Шулар арасыннан Исмәгыйл Зәйдуллин кебеге, әнә, су асты көймәсенең командиры булган, 1930 елларда ук үз көймәсе белән Төньяк флот аша Владивостокка кадәр су астыннан үтеп рекорд куйган, ә 1944 елда Ленинградны саклап һәлак булган.

Хәер, тарих сандыгының төбенәрәк чумсак, Йосыпов, Шереметов, Урусов, Ураков атлы чукынган татар морзалары Петербург каласын XVIII гасырда ук билбавыннан эләктереп алган инде. Шулар тырышлыгы белән 1812 елда Наполеонга каршы көрәшкә Польша һәм Литва татарлары 2 нче улан полкын төзеп биргән һәм алар бу яуда тиңсез каһарманлыклары белән дан алган. Тора-бара Петербургтагы татарларга Нижгар, Пенза, Казан якларындагы сәүдәгәрләр килеп өстәлгән. Шулар арасыннан Атаулла Баязитов 1892 елда ук патша исеменә татарча газета чыгарырга рөхсәт сорап мөрәҗәгатьләр юллаган. Ниһаять, рөхсәт алуга ирешкәч, 1905 елда Петербургта Казан татарларының беренче газетасы «Нур» пәйда булган. Шул ук Атаулла хәзрәт башлангычы белән башкалада мәчет булдыру өчен көрәш башланган. Акчаны полковник Габделгазиз Дәүләтшин (тумышы белән Башкортстан татары, 1917 елгы революция вакытында – Төркестан хәрби округының командующие, генерал-майор) җитәкчелегендәге комитет Бөтенроссия буенча җыйса да, төп керемне Бохара әмире Сәет Габделәхәт ясаганга күрә, булачак мәчетне дә шәрык өслүбендә корганнар. Гәрчә төзелеш тулысынча тәмамланып бетмәсә дә, Романовлар династиясенең тәхет яулавына 300 еллык юбилейга туры китеребрәк, тәүге намазларны 1913 елда укый башлаганнар.

Аннары Петербург – башкала булганга күрә, Николай патша фәрманы буенча, Дәүләт Думасының 1 нче чакырылыш депутатлары да шушында җыела бит. Демократия дигән уен Россиягә җиңел генә үтеп керә алмый, берничә ай узгач ук беренче чакырылыш депутатларын куып тараталар. Ә икенче чакырылышта инде Дума составына барча депутатлар арасында бердәнбер булып Франциянең Сорбонна университетын тәмамлап кайткан Казан егете Садри Максуди да сайлана. Нәкъ менә шушы депутат Россиянең Дума делегациясен җитәкләп Англиягә бара һәм анда саф француз телендә җәмәгатьчелек палатасы вәкилләре алдында чыгыш ясый. Һәм шушы ук депутат комиссияләрдә һәм Дума мөнбәреннән йөз мәртәбә чыгыш ясап, Россиянең мәгариф турындагы законына «мөселман балалары башлангыч мәктәптә фәкать үз телләрендә генә белем алуга хокуклы, аларга рус теле өлкән классларда гына укытыла ала», дигән төзәтү кертүгә ирешә. Шул ук Максуди Хәрби законга «Патша мөселман илләренә каршы сугыш игълан итсә, Россиядә яшәүче мөселман халыклары ул сугыштан азат ителә», дигән искитмәле төзәтмә кертү буенча да җиңеп чыга. (Шуннан соң бер тиенгә кирәксез Әфган сугышында Татарстан җиреннән чакырылып һәлак булган 777 солдат күз алдына килә дә, йөрәк гел «аһ» итә!) Һаман бер үк Максуди законга «мөселман авылларында кабаклар ачу тыела», дигән төзәтмә кертүгә дә ирешә бит әле! (Ә безнең бүгенге депутатларның татар телен шатырдатып кискән һәм итекләр белән таптаган чагында да «ыһ» иткән тавышы да чыкмады.) Әмма ни үкенеч, 12 ел буе башкалада яшәгән һәм татар милләте өчен амбразурага ташлангандай көрәшкән Садри Максудиның, аның янына иңгә-иң куеп баскан Һади Атласи, Ибниәмин Әхтәмов, Әкрам Биглов, Гариф Бәдамшин, шушында ук «Ил» газетасын чыгарып газиз милләтен яклаган Гаяз Исхакыйның, тау институтында белем алган Мулланур Вахитовның бүген Петербургта сынар эзе дә юк!..

1918 елда Гражданнар сугышы башлангач, Петроградта ятим калган мөселман балалары өчен 4 махсус мәктәп ачылган, 1921 елгы ачлык вакытында ятим калган татар балалары өчен М.Вахитов исемендәге махсус клуб та оештырылган. Хәтта әле Бөек Ватан сугышына чаклы Ленинградта 55 номерлы мөстәкыйль татар мәктәбе дә эшләп килгән.

1937 елда Сталин җәлладлары кузгаткан «Кызыл террор» вакытында Ленинград өлкәсеннән 50 меңгә якын кеше төрмәләргә озатылган, аларның 15 меңнән артыгы атып үтерелгән. Ул юк ителгәннәр арасында меңәрләгән татар, шул исәптән атаклы Атаулла Баязитовның улы,Уфа каласында мөфти булып торган Мөхәммәтсафа Баязитов, Г.Тукайның дусты, «Шимәль ягы» исемле татар газетасының редакторы Кәрим Сәгыйть тә бар...

Без Петербургның иҗат үзәгендә, Ленинград өлкәсенең Халыклар дуслыгы йортында, Россиянең төньяк-көнбатыш регионнары мөфтие Равил хәзрәт Панчеев җитәкләгән үзәк мәчеттә, Кызыл авыл дип аталган бистәнең Габделбәр Алимов җитәкләгән милли-мәдәни үзәгендә, Эрмитаж һәм Россиянең этнографик музеенда, шулай ук Анна Ахматова белән Лев Гумилев яшәгән музей-квартирада очрашулар үткәрергә өлгердек. Аңлашыла булыр, төп сүзебез җанисәп вакытында татар халкының саны кимү өчен әрнү-яну иде.

(Дәвамы 16 нчы биттә).

● Безнең делегация Петербург мөфтие Р.Панчеев (уңда) белән.

● Безнекеләр «Аврора» крейсеры янында.

Башкортстан кызы – милли рәссам

Казан Ратушасындагы «Окно» картина галереясы Башкортстанның атказанган рәссамы, дизайнер, сәнгать өлкәсендәге Ш.Бабич исемендәге премия лауреаты Чулпан Билалованың «Далалар җиле» күргәзмәсе былтыр, күпсанлы сәнгать сөючеләр үтенече буенча, шактый озайтылды.

Чулпан Билалова үз иҗатында абстракт реализмга өстенлек бирә. Ул чираттагы күргәзмәсенә бу юлы да картиналары белән берлектә график хезмәтләрен дә урнаштырган. Шушы график битләр буенча гына фикер йөрткәндә дә рәссамның иҗаты янә сокландыра. График темаларның күбесе борынгы әкиятләр белән дә бәйле. Рәссам күп китапларны, шул исәптән әкият китапларын бизәү белән теләп шөгыльләнә. Ул бизәгән китапларга балалар да, олылар да гашыйк. Һәр рәсем җанлы сюжет, экспрессив мохит, пластика, күп детальләр, куәтле фантазия белән баетылган. Аның күп кенә хезмәтләре Россия, Нидерланд, Франция, Италия, Германия, Португалия, Сербия һ.б. дәүләт туплanmaларында саклана. Чулпан Билалова – Мәскәү һәм Россия Рәссамнар берлеге, Россия һәм Башкортстан Журналистлар берлеге, ЮНЕСКО Рәссамнарның халыкара ассоциациясе сафында. Чулпан ханым «Пресса-2007» XIV Халыкара профессиональ күргәзмәсенең «Золотой фонд прессы» номинациясендә җиңеп, дипломга лаек булды. 2005 елда ЮНЕСКО эгидасы кысаларындагы «Цивилизацияләр диалогы» Халыкара иҗат экспедициясендә катнашкан чакта Парижның Поль Горсен сараенда шәхси күргәзмәсен ачты. Аның әсәрләре Норвегия, Швейцария, Нидерландта узган халыкара арт-симпозиумнарда уңыш казанды. 2021 елда Чулпан Билалова Бөтендөнья башкорт корылтае башкарма комитеты тарафыннан «Ал да нур чәч халкыңа» медале белән дә бүләкләнде.

Чулпан Борайда туып үскән. «Үземне белгәннән бирле рәсем ясыйм, – ди ул. – Балалар бакчасында чакта биергә, ясарга яраттым. Балерина яки рәссам булачакмын дип сөйләнә идем. Рәсем укытучыларым да булмады, сынлы сәнгать мәктәбендә дә белем алмадым. Урта мәктәптә төгәл фәннәрдән дә гел бишле билгеләре алып кына укыдым, шуңа күрә әтием: «Кызым, бәлкем, синң математика укытучысы булып китәргәдер?» – ди иде. Әнием Сәкинә дә, әтием дә рәссамлык шөгылемне дәвам итүемә каршы килмәде. Мәктәптән соң Башкорт дәүләт педагогика институтының сынлы сәнгать-график факультетын тәмамладым. Аннары Дүртөйле шәһәрендә рәсем һәм сызым укытучысы булып эшләдем, соңрак Уфаның 2 нче педагогика көллиятендә укыттым. Һәм 2007 елга кадәр республиканың «Акбузат» балалар-яшүсмерләр журналында башта – бүлек мөдире, аннары җаваплы сәркатиб вазыйфаларын башкардым.

2007 елда кызым Элиза, улым Олег белән Мәскәүгә күчендек. Миңа берничә эш урыны тәкъдим иттеләр, «АРС Комьюникейшнс» компаниясенең арт-директоры буларак хезмәт куйдым. 2016 елдан башлап, менә инде 7 ел, мин – ирекле рәссам».

Ч.Билалова төрле жанрлардагы әсәрләр иҗат итә. Әмма иҗат темасында бер даимилек күзгә ташлана: ул еш кына балачак хатирәләрен сурәтли. «Әсәрләрем арасында туган ягым Борайга, Хәйбулла районының Әбүбәкер авылына да багышланганнары бар, – ди әңгәмәдәшем. – Ташлы елгасы да гел исемдә. Балалар китапларына заказ алгач та, илһамланып эшкә керешәм, өлкәннәр һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләү күңелемә хуш килә».

– Чулпан, сез бихисап әкият каһарманнарын да сурәтләгәнсез, башка әсәрләргә дә алынгансыз...

– Мин Мәскәүдәге «Детская литература» нәшрияты белән хезмәттәшлек итәм. Зәйнәп Биишева исемендәге «Китап», «Демиург» нәшриятлары белән дә. Классик әсәр буенча «Шәһрезадәнең 1000 дә 1 кичәсе» иллюстрацияләр циклым да бар, башка әкиятләргә дә рәсемнәр ясалды. Иллюстратор буларак, 32 китап бизәдем, инде 1000 иллюстрация иҗат иттем, алар бик төрле. Китап бизәү – катлаулы, озак процесс. Мин иллюстрация ясауга җитди карыйм. Рәссам тырыш булырга, көненә унлап-егермеләп эскиз әзерләргә тиеш дип саныйм. Эшемдә майлы буяуларны да, акрил, типография буяуларын да, төсле каләмнәрне дә кулланам... Әкият композицияләрен әзерләгәндә, сихри мохит килеп чыксын өчен, кәгазь битләренә сабынлы сулы басма, эстамп та чәпим, ул сабынлы суга төсле пигмент кушып ясала, фон килеп чыккач, каләм белән композиция өстим.

Башка төр китапларга килгәндә, быел, апрельдә Ренат Беккинның «Ак буре. Крымскотатарская сага» романы бизәлешен башкардым. Аның төп вакыйгалары Казанда башлана, аннары алар Ташкент, Мәскәү, Кырымга илтә. Әсәр магик реализм элементлары кушылган роман-мәҗарадан гыйбарәт, бу гаилә сагасы 1920-2014 елларны колачлый һәм Кырым татарлары гаиләсенең өч буын тарихын тасвирлый. Рәсемнәрем аша сюжет линиясен күрсәтеп бирергә омтылдым. Әгәр режиссёр булсам, бу роман буенча кинофильм төшерми калмас идем!

– Былтыр да сез күп мәдәни чараларда катнашкансыз...

– Шулай. Май аенда «Ташлар җыючы» шәхси күргәзмәм Алабуганың Заманча этносәнгать музеенда узды. Иҗатымда реализм, экспрессионизм, импрессионизм, абстракция – һәммәсе дә бар бит.

Алабугада үткәрелгән халыкара арт-симпозиумда да, Борайда оештырылган «Танып-су» II Бөтенроссия этно-арт-симпозиумында да теләп катнаштым. Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы тарафыннан үткәрелгән заманча сәнгать буенча XVII Халыкара арт-симпозиум быел «Хезмәт симфониясе» дип аталды һәм бу юлы да төрле халыкларның милли традицияләрен сәнгати интерпретацияләүне үз эченә алды, чара кысаларында «Тракторчы» һәм «Кыргый бал» хезмәтләремне тәкъдим иттем. Соңгысы Башкортстанда сакланып калган чолыкчылык шөгыленә багышланды. Чолыкчылык, белгәнегезчә, ул бал җыюның бик борынгы төре. Кыргый бал кортлары агач куышларына бал җыя һәм мондый куышларның табигыйләре дә бар, алар юан агачларга дүрт метрдан алып унбиш метрга кадәрге биеклектә кешеләр



тарафыннан да ясала. Кайчак агач пүләненнән махсус ясалган куышларны агач ботакларына да элеп куялар. Башкортстанда урман эчләрендәге кыргый бал әлегәчә шушы ысулда җыела...

Әлеге арт-симпозиумда Россия, Азәрбайҗан, Казахстан һәм Үзбәкстаннан 35 рәссам катнашты, без, һәрвакыттагыча, яңа техникалар белән таныштык, осталык дәресләре үткәрдек. Моннан тыш Алабугада узучы Үзенчәлекле рәсем биеннале кысаларындагы Бөтенроссия конкурсларында да катнашырга яратам. Әйтик, 2021 елда да минем рәсемем анда җиңү яулады.

– Сезнең остаханәгез Нидерландта да бар иде...

– Бар, ләкин ул ябык. Кызганыч, мин хәзер Нидерландка барып йөри алмыйм. Моңа сәяси вакыйгалар комачау итте. Әмма әсәрләрем Геффен каласындагы картина галереясындагы бер залда даими экспозициядә, иҗатымдагы күп фигуралы композицияләрне анда да һәрчак ошатып кабул итәләр. Моңа кадәр чит илдә осталык дәресләре дә үткәрдем. Менә шул шәхси галерея директоры Юстинус Ван Нистерлоой картиналарымны бик ошата. Галереяның икенче катында – остаханәләр, шуларның берсе – минеке.

– Иҗатыгызда нинди яңалыклар бар?

– Былтыр февраль аенда Эфиопиянең Аддис-Абеба каласында узган AIAS – Халыкара сәнгать симпозумында катнашкан идем, бу сәнгать күргәзмәсе социаль челтәрләрдә популярлык казанган хәрәкәтнең үзенчәлекле арт-проекты булды. Бу – ялган яңалыкларга, Көнбатышның чит дәүләтләр сәясәтенә тыкшынуларына, неоколониализм, тотрыклыкны юкка чыгаруга каршы юнәлдерелгән начарлыкларга каршы, АКШның башка милләтләрне үзара дошманлаштыруына каршы көрәш чарасы. Симпозиум каталогына минем «Кораб. Сүзсез!» һәм «Тынычлык кошы» эшләрем дә кертелде.

– Тонлы кәгазьгә «Тигез сугыш» әсәрен дә ясагансыз. Ул нинди хис-кичерешләр аша иҗат ителде?

– «Тигез сугыш» – 2022 елдагы төп хезмәтем. Аны март аенда ясадым. Без – күп вакыйга шаһитлары, әлбәттә, бүгенге вакыйгаларга карата мөнәсәбәт теләсә кайсы рәссам иҗатында да чагыла. Мин аны махсус ясамадым да кебек, шулай килеп чыкты. Кайчак рәссамга үз хис-кичерешләрен сүзләр белән әйтеп бирү кыен һәм куллар үзләреннән-үзләре киндергә үрелә. Сюжет туа. Ясап бетергәч, аңа башка күзләр белән карадым. Әлеге үгезләр – капма-каршылык, алар икесе дә көчле, аларның бер-берсен җиңәселәре килә. Бу – символика. Алар җир тырнап көч сынаша. Өсләрендә – зур Космос, Күк йөзе, Киек Каз юлы, йолдызлар... Менә алар исә – мәңгелек, ә кешеләр һаман көч сынашудан туктый алмый.

– Иҗат процессында, вакыт үтеп, идея онытылган, образ, сюжет композициясе ясалганчы ук хәтердән җуелган чаклар буламы?

– Андый хәлләр дә булгалый, кайчак вакыт җитми кала, кайчак төшләрдә матур сюжетлар күрәсең, ә алар тиз арада онытыла... Мондый күңелсезлекләрдән башка төр рәсемнәр ясый башлап котылам, алар үзем теләгәнчә яхшы килеп чыккач, күңелемдәге моңсулык та тиз арада юкка чыга. Моңсуланырга да ярамый. Рәссамның рухы көчле булырга тиеш. Шуңа күрә яңа рәссамнар белән дә бик теләп аралашам, яңа әсәрләре белән танышам, музейларга, күргәзмәләргә йөрим. Әдәби китаплар укый башлагач та, андагы вакыйгаларны уем аша үземчә җанландырам, рәсем идеяләре туа. Эскизлар тирә-юньдәге кешеләрне даими күзәтүдән дә барлыкка килә. Әмма балалар рәсемнәрен ясау – иң күңеллесе. Аларны балачакка хас ваемсыз, ихлас итеп сурәтлим. Гомумән, ак кәгазь күрүгә үк кулларым кычыта башлый, аңа тиз арада күңелле рәсем ясап куясым килә!

Башкортстан да гел күңел түрендә, Мәскәүдән аны сагынып кайтам, илһам алып киләм. Әсәрләремне милли колорит аша корам, милли кием-салымнар, бизәкләр ясап куәтлим, традицияләребезне барлыйм, кеше йөзләренә дә башлыча башкорт һәм татар йөз чалымнарын салам. Казандагы «Далалар җиле» күргәзмәмнең вакыты озайтылуын ишетеп тә шатландым. Биредәге тамашачыларның, сәнгатемне үз итүчеләрнең аны җылы кабул итүен белү – зур куаныч! Безнең күрше республикалар, туганнар кебек дус, тату булып, бәрәкәттә яшәсен дигән теләктә калам!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Казан басмасы яңарды

Татар өммәтенең иң зур рухи ядкәре – 1803нче елда Казан типографиясендә басылган Коръәннең «Казан басмасы», хәзерге заман фәнни һәм басма стандартларга туры китерелеп яңартылганнан соң, беренче тапкыр классик мөсхәф (җыентык, тупланма) рәвешендә дөнья күрде.

Күптән көтеп алынган китапны Татарстан мөфтияте «Казан басмасы»ның 220 еллыгы һәм Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кысаларында чыгарды. Исегезгә төшерәбез, «Казан басмасы» – «Ар-Расм Әл-Усмани» стандартына туры килгән, ислам галимнәре тарафыннан кабул ителгән һәм бар мөселман дөньясына танылган һәм таралган беренче басма Коръән. Басма үзенең уникаль һәм уңайлы типографик шрифты белән дан казана.

Яңартылган «Казан басмасы» мөсхәфе Татарстан мөфтиятенең Коръәнне бастыру өлкәсендә татар традицияләрен торгызу эшчәнлегендә соңгы этап булды. Моның өчен 2021 елда «Казан басмасы»ның тарихи типографик оттискыннан шул ук исемдәге уникаль компьютер шрифты эшләнде. Хәзерге компьютер символлары Казан Коръәне шрифтының чын тарихи йөзен саклап кына калмыйча, Коръән һәм китап бастыру өчен яңа заманча техник мөмкинлекләр дә ачты.

Алга таба 2022 елда Нәзарәт белгечләре «Казан басмасы» дип исемләнгән татар милли компьютер шрифты белән Коръән текстын яңадан җыйды һәм, күренекле татар галимнәре Шиһабетдин Мәрҗанинең «Фәваид әл-Мухиммә» китабындагы һәм Муса Бигиевнең «Тасхих расми хат» китабындагы искәрмәләрен исәпкә алып, заманча халыкара стандартларга туры китереп басмага әзерләде.

Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм итү фонды белән берлектә «Казан басмасы»н мөсхәф рәвешендә югары заманча сыйфатлы итеп, уңайлы форматта (А5+), сәнгати бизәлеш белән бастырып чыгарды.

ПЕТЕРБУРГКА СӘЯХӘТ

●Петербургның Казан урамындагы 5 нче йорт диварына Г.Тукай яшәп алу хөрмәтенә куелган истәлек тактасы.

● Этнография музееның Мәрмәр залында татар крестьяны гәүдәләндерелгән почмак.

● Этнография музеенда татар кибете күренеше.

(Ахыры. Башы 12 нче биттә.).

Әле 2010 елда гына 30 мең дип күрсәтелгән татар халкының саны хәзер Петербургта 20 меңгә калуына бер генә кеше дә ышанмый. Ә Петербург татарларының милли-мәдәни автономия рәисе Рәис Яркәев һичкемнән дә тартынып тормыйча, шундук ярып сала:

– Илдә шартына китереп, тиешенчә җанисәп алу үткәрелмәде, исәпкә кергән татарлар санын да кискәләп һәм йотып бетерделәр. Иманым камил, бүген Ленинград өлкәсендәге татарлар саны 600 мең чамасы исәпләнә. Безне капчыкта озак вакыт буе яшереп йөртеп булмый, ул без киртәләрне җимереп чыгачак һәм хакыйкать тә ачылачак әле...

Без үзебез дә моңа шикләнмибез. 1990 елдан соң Россиядән чит илләргә чыгып киткән качакларның санын хәзер инде 30 млнга җиткереп исәплиләр. Үлем-китем дөньяның бер генә иле белән чагыштырмаслык дәрәҗәдә. Ә карагруһчылар һаман Рәсәй халкын 147 млн, ә урысны 106 млн, дип тәкрарлый. Вәт әкәмәт, маржа хатыннары бала тапкан чакта татар, башкорт, якут, бурят, мари, чуаш... ирләре вә хатыннары йоклап ятамыни?!.

Татарларның бердәмлеге турында сүз кузгаткан чакта моны Петербург мөфтие Равил хәзрәт Панчеевтан да остарак аңлатып бирү мөмкин түгелдер:

– Бер гасыр элек, большевикларның Октябрь түнтәрешенә чаклы Россиядә татарларны бер генә көч тә Пенза яки Нижгар, Әстерхан яки Кырым татарларына бүлеп йөртмәгән бит. Һәммәбезнең теле бер, барча мәдрәсәләребез дә уртак булган. Нижгардан килгән татар да, хәтта Урта Азиядән үк килеп җиткән шәкерт тә рәхәтләнеп бер үк «Мөхәммәдия» яисә «Галия» мәдрәсәсенә кереп укый алган. Иж-Буби мәдрәсәсендә, әнә, хәтта биш телдә берьюлы укытканнар, шуңа күрә аларның шәкертләре Төркия генә түгел, Голландия университетларына да барып керә алган. Мөгаллимнәре дә, мисалга – Петербургтагы Муса Бигиев яки Себердән күтәрелгән Габдрәшит Ибраһимов, рәхәтләнеп Каһирә университетларында белем биргән. Революциядән соң безне таркатканнар. Имеш, син Нижгар мишәре, икенчесе – Себер татары, әлләни сикереммә, урыныңны бел дә тын гына утыр. Нәтиҗәдә Себер белән Казан татарларының, Кырым белән Казан яки Әстерхан татарларының элемтәсе, үзара килен алмашу, дуслык-туганлык өзелде. Бер-беребезнең кайгы-хәсрәтенә күз йомарга, ишетмәмешкә өйрәндек. Үзебезнең хуҗалык имин икән, Аллага шөкер, ә Себер яки Әстерхан татарының өй түбәсе ник ишелеп төшми. Безне мәнә шулай итеп тар араннарга куып керттеләр, без гыйлем алмашу һәм аны ишәйтүдән ерагайдык. Шуңа күрә безне хәзер сыңар йодрык, сыңар фәрман белән дә авызлыклап тору җиңел. Әгәр без мәнә шушы киртәләрне җимереп чыга алмыйбыз икән, аннары «бетәбез бит», дип елап утырудан бер мәгънә дә юк...

Төрле кала һәм төрле җәмгыять җитәкчеләре белән очрашкан вакытта да аеруча бер теләк көчле яңгырады:

– Каланың яки берәр районның кайсыдыр почмагында мунча шикелле генә йорт һәм аның эчендә оешма төзеп куюлләни авыр түгел. Ләкин ул вак учакларның яктысы да еракка ялтырамый, җылысы да сүлпән, вакытлыча. Татарстанның Петербург җитәкчеләре белән килешерлек абруйлары ныклы. Безгә Петербургның үзәгендәрәк бер урында җир сатып алырга иде дә, шунда идарәсе дә, музей һәм сәнгать түгәрәкләре дә сыярдай мәһабәт бер үзәк булдырырга иде. Татарлар күп, ә аларның һәммә милләт, һәммә җитәкче санга сугардай күмәк учагы юк. Татарстан җитәкчеләре шушыны хәл итсә, без дә йөкне уртак җилкәләргә күтәрерлек сәрмаясын да, терәген дә табар идек әле...

Дүрт тәүлек буе Петербург каласы буйлап йөргәндә үзебез өчен сабак та алмый калалмадык. Петербург – мәйданы буенча безнең Казан каласыннан өч мәртәбә зуррак, халкы 5,5 млн. Мәйданы өч тапкыр зуррак булса да, Петербург урамнарында бер табакка җыярлык кар өеме дә юк. Билгеле, биредә хәтта кыш урталарында да яңгыр яугалап тора, кары да күп булмый, әмма шул килеш тә һәр төн саен зур-зур самосваллар белән шәһәр читенә кар өеме чыгаралар. Ә бездә гыйнвар ае узып китте инде, әмма кайсы урамны гына ахырына кадәр, намус белән чистартып чыктылар соң? Аннары, машиналар саны 4 млнга җитеп килсә дә, Петербург урамнарының берсенә дә Казандагы кебек богау салынмаган. Кем кайда яши, шул кеше үзенең йорт каршына, юл читенә машинасын куя да өенә кереп китә, аларда Казандагы шикелле камераларга төшереп йөрүче, ахырдан штраф таләп итүче, асфальт өстеннән дә акча эскертләре җыючы «асаба» гаиләләр юк. Революцияләр башкалаларда тамыр җәя һәм чәчәк ата, дидек бит, ә Казанга андый дулкын килеп җитмәгәндер. Нәкъ С.Хәкимчә: «Казан әле, Казан уянмаган»...

Кайту юлына чыккач, безне шәһәрдән Пулково аэропортына чаклы гадәти бер такси илтеп куйды. Тел тик тормый бит, үзара гәпләшәбез. Шунда такси хуҗасы Петербург каласының иң олы бер серен ачып ташлады бит:

– Мәнә бу хәрби операция башланганнан бирле Финляндиядәге йортыма бара алганым юк. Чик буен корыч йозакка бикләп куйдылар. Андагы иң матур күл буендагы бер гектар җирне һәм ике катлы йортны 2002 елда ук сатып алган идем. Хәзер салымнарны да, коммуналь чыгымны да түләп барырга туры килә. Йортны сатып та булмый.

Баш түбәсен бер генә уй ут шикелле кыздырып бораулый, эндәшерлек хәл юк:

– Без дә яшибез, дип аталабыз, адәм тәганәсе!..

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

● Эрмитажга куелган Мисыр фиргавененең саркофагы.

●Эрмитажда Себер осталары әзерләп, 150-180 ат җигеп китергән, 19 тонна авырлыгындагы чаша янында.

«Әйт әле, ни өчен хакыйкать, Аклыктан карага үрелә?»

Бүген яшьләр матди байлык артыннан куалар, рухи яктан бик ярлы дип сөйләргә яратсак та, арада күңел хисләренә бай, дөньяга рухи күзлек аша карый белүчеләре дә аз түгел. Моны яшь шагыйрьләрнең бер-бер артлы шактый матур китаплары басылуы да раслый. Азнакай шәһәрендә яшәп иҗат итүче Алинә Хисамиева шундыйлардан.

Башкалада, шигъриятка килүчеләр арасында, нигездә, татар филологиясен яисә журналистика факультетын бетерүчеләрне еш күрергә туры килә. Нефть төбәгендә исә, нефть тармагында хезмәт куючылар, шул юнәлештә белем алып шигърияткә тартылучылар аз түгел. Алинә югары белемне Әлмәт дәүләт нефть институтында ала. Шунда укыганда, институтның «Әдәби кунакханә»сенә йөреп, каләмен шомарта. «Сәләт» лагеренда чыныгу уза. «Кызыл каурыйлар» әдәби берләшмәсендә үзенең иҗаты белән өлкән каләмдәшләрен таныштырып, аларның хәер-фатихасын ала. Укуын тәмамлагач, Алинә туган ягы – Азнакайга кайтып китә.

Былтыр Алинә Хисамиеваның Татарстан китап нәшриятында «Канатсыз очкыч» исемле шигырьләр китабы басылып чыкты. Әлеге җыентык аның өлгергән, чын шагыйрә икәнен раслады.

Алинә Хисамиева бик күпләрнең рухына тәңгәл килә торган, аларның күңел халәтләрен чагылдыра торган шигырьләр иҗат итүе белән игътибарны җәлеп итә. Аның шигырьләренә Илдус абый Гыйләҗев, Клара апа Булатова кебек олпат шагыйрьләр үзләре фатиха бирде.

Автор каләменә тирән лиризм, әчке бәргәләнү, хисләр көрәше хас.

Көтеп-көтеп һич ялмаган карым,
Карсыз тәүге кышым син минем!
Язлар булып буран даулый күңел...
(«Җырланмаган җырым»)

Шагыйрәдә хатын-кызлар гына күрә, сурәтли ала торган серле сөю, буталган, тәртибе югалган хисләрнең тәртибен үзе генә белә, аңлый торган үзгә бер дөнья. Алинә Хисамиевада чын хатын-кыз сөюе: каршылыклы, ирләр генә түгел, үзе дә аңлый һәм аңлатып бирә алмый торган хисләр ташкыны.

Вакытлыча булды ташу,
Ут янды тиздән.
Дөньябыз да зыр-зыр килеп,
Чапты бер эздән, –

дип яза шагыйрә «Ут сүнү» шигырендә. Ләкин шәм сүнсә дә, лирик герой күңеленә яктылык элеп калдыра. Кеше өчен, кеше булып яшәү өчен бу – бик зур әйбер. Чөнки, кешенең җанында шәм сүнү, җылы бетү, ялкын кимү – ул фаҗига. Алай булса кеше яшәү мәгънәсен югалтыр иде. А.Хисамиева шигырьләрендә һәрвакыт башкаларга яшәү көче бирә, өмет уты кабыза белә.

Яшь булуына карамастан, Алинә Хисамиева җиңел мәхәббәт такмаклары белән мавыкмый. Тормыш чынбарлыгын яктырткан кырыс, усал шигырьләре дә шактый. Чөнки, шагыйрә тормыштагы гаделсезлек белән килешеп яшәргә теләми, аңа үзенең кискен мөнәсәбәтен белдерә.

Сулышыны куыра бу халәт,
Йөз төсмер югыйсә күңелдә.
Әйт әле, ни өчен хакыйкать
Аклыктан карага үрелә?!
...Әйт әле, ни өчен бу галәм
Мактауны, ялганны ярата?! –

(«Ак челтәр шәүләсе») дип ачына автор. Укучыга соравы ачык калган. Бәлки, автор үзе дә җавап таба алмыйдыр яки башкаларны уйланырга чакыра? Шагыйрьне аклыкның каралуы, хакыйкатьнең ялганга уралуы,

«милләтем» дигән сүзнең, ул хакта сөйләүнең дөреслектән читтә торуы борчый.

Йөземдә ак челтәр шәүләсе,
Тоныклык эчендә сурәтем.
Әйт әле, ни өчен карала
Сүзләрем... сөйләмем... милләтем?!
(«Ак челтәр шәүләсе»)

Еллар буе хөкем бара,
Орып-орып җанны ташка...
(«Хөкем залы»)

А.Хисамиева матурлыкның бу дөньяда кыска вакытлы күренешкә әйләнеп баруын ассызыклый. Тик бу бик тә нәзакәтле, нәфис итеп, берәүне дә гаепләмичә бирелә.

Җуелган җылысын җанымның,
Җәйләрдән табалмый аптырыйм.
(«Халәт»)

Шигырьләрендә автор үзен эзли, үзе белән бергә «керләнмәгән хисләр эзли». Ел фасылларыннан, яшеннән, яңгырдан, төн карасыннан, ай яктысыннан, җәйге челләдән эзли. Билгеле бер вакыт аралыгында таба да тагын югалта. Ул хәтта вакыт-вакыт үзеннән дә канәгать түгел. А.Хисамиева иҗатында кыш, буран образлары өстенлек ала. Тик алар кузгаткан хисләргә акылы каршы чыга. А.Хисамиева шигырьләренә акыл белән хисләр көрәше хас. Ул эчке көрәшне оста чагылдыра.

Боз кисәгән кырып-кырып,
Тырмый хәтер, дөрли җаным.

Автор үткәннәрен куктә агып барган болытлар белән тиңли. Болытларның да аклары белән. Алар матур. Чыннан да, ничек кенә булмасын, үткәннәр матур бер хатирә булып яши хәтер төпкелендә. Ә алар агалар да китеп баралар.

А.Хисамиева иҗатында «әтиле этисезләр» темасына күп игътибар бирелә. Шагыйрә әтиле килеш әтисез булып йөрүче балаларның хис-кичерешләрен психологик төгәллек белән, күпертми, арттырмый, ясалма, өстәмә кичерешләр кушмый гына тасвирлап бирә. Чөнки авторның үз йөрәге, үз күңеле аша үткәннәр.

... Ул очрады беркөн. Җитәкләгән
Сөйгән ярын, үги улларын.
Букчам кесәсеннән бүләгемне
Калтыранып эзли кулларым.
(«Кәгазь очкыч»)

Автор сүзләрнең шундыен таба, алар лирик герой йөрәгенә генә түгел, ә канатсыз кош җиргә кадалган кебек, укучы җанына да кадала.

Гомумән, ата-ана, бала темасы Алинә Хисамиева иҗатының үзәге дияргә мөмкин. «Күп җыела иде кесәләрдә, көймә, очкыч» ди автор. Юк, андый бүләкләр лирик герой кесәсендә генә түгел, кул сузымы гына җирдән үтеп йөргән, тик «әти», «әни» сүзен әйтергә тилмергән бик күпләрнең кесәсендә җыелган. Әле хәзер дә җыеладыр.

Бер әйтергә мең тилмергән сүзем
Үзем язам. Үзем кабатлыйм.
(«Кәгазь очкыч»)

...Гел ялангач мәле җанның.
(«Челтәремдә – котлавым»)

Әйе, лирик геройның дөньясы җитеш. Тик шулай да... вакыт-вакыт күңелгә кемдер, нәрсәдер җитми. Автор хатын-кызга хас наз тулы хисләр диңгезендә йөзә дә, кинәт кенә «комга утыра» һәм кырыс чынбарлыкка кайтып төшә.

Юк, үкенмим! Бүген барыр юлым,
Бәлки бәхетләрәк синнән башка...
(«Синсез»)

А.Хисамиеваның шигъри табышлары да аз түгел. «Кояш бүген җирдән атлый төсле», «җәйне сулыйк», «җан ишеге», «җәй җилгә ияреп йөри» кебек гыйбарәләрдә автор укучыга үз дөньясын, үз җанын ача. Гомумән, фәлсәфи фикерле, хисләр ташкынын үз иркенә куйган шагыйрә Алинә Хисамиева иҗаты үз укучыларын, исеме үз урынын табар дип ышанып калам.

Рәфкать ШАҺИЕВ.

Айга карама / Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

28 гыйнвар (шимбә). ***Рәҗәб аеның 6нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 10.57 сәгатьтә калка, 2.08 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.20 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Мандарин шифасы

Бу гаҗәеп тәмле җимеш искиткеч сихәтле дә. Мандаринда калий, магний һәм кальций бар. Ә менә нитратлар беркайчан да булмый – җимештәге лимон кислотасы зарарлы матдәләрне юкъяшәтми. Мандарин организмдагы матдәләр алмашын яхшырта, аппетитны көчәйтә, ашкайнатуны җайга сала, авитаминоздан саклый. Мандарин кабыгы диарея һәм бронхитны дәвалауда кулланыла, киптерелгәне исә үзәк нерв системасын тынычландыра һәм авыртуны баса.

29 гыйнвар (якшәмбе). ***Рәҗәб аеның 7нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 11.07 сәгатьтә калка. 2нче фаза. Көн озынлыгы 8.25 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

Кан басымын төшерү

Кан басымы югары булганнар өчен тәүлеклек тоз микъдарын 5-6 миллиграммнан арттыру зыянлы. Гипертониклар өчен магний – иң кирәкле микроэлементларның берсе, аңа урман чикләвеге, соя, яшел тәмләткечләр бай. Кальций да кан басымын төшерә, ул күрәгә, инжир, кипкән балыкта, сөт ризыкларында күп. Нормадан арткан һәр 4-5 кг авырлык артериаль кан басымын 5 миллиметрга күтәрә. Көн саен 2-3 чакрым җәяү йөрү исә кан басымын төшерә, йөрәктә ишемия авыруы, шулай ук диабет килеп чыгу ихтималын киметә.

30 гыйнвар (дүшәмбе). ***Рәҗәб аеның 8нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында,11.21 сәгатьтә калка, 3.34 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.29 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Ютәлдән дәва

Өлгергән банан йомшагын изеп, өстенә кайнап торган су яки сөт агызалар, яхшылап болгаталар. Йокларга ятар алдыннан кайнар килеш эчәләр. 3 көн рәттән эчәргә кирәк.

31 гыйнвар (сишәмбе). ***Рәҗәб аеның 9 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 11.41 сәгать-***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

тә калка, 4.58 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.33 сәгать.

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уяныргa мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

1 февраль (чәршәмбе). ***Рәҗәб аеның 10 нчы көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 12.10 сәгатьтә калка, 6.15 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.36 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Ябыгабызмы?

Чамадан артык ашамас өчен, күбрәк эчәргә кирәк, бигрәк тә минераль су, яшел чәй яки сөтле кара чәй эчү файдалы. Баллы чәй һәм сокларда исә калорияләр бик күп, шуңа тыелу зарур. Симермәс өчен, организмны ач тотып интектермәскә кирәк – бу очракта ул майны запаска туплый башлый. Иртән әйбәтләп ашаганнан соң, 4 сәгатькә бер аз-азләп ашап алырга кирәк. Кичке ашны йокларга ятарга 3-4 сәгатьтән соңартырга ярамый. Ә менә бу яшелчәләрне симерүдән курыкмый ашарга була: брокколи, ташкабак, әспе, чәчәк кәбестә, сельдерей, кыяр, баклажан, яшел фасоль, салат, суган, редис, яшел борыч, кабак, помидор, цукини.

2 февраль (пәнҗешәмбе). ***Рәҗәб аеның 11 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 12.53 сәгатьтә калка, 7.19 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.40 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

3 февраль (җомга). ***Рәҗәб аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 13.52 сәгатьтә калка, 8.06 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.44 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Лимон кесәле

650 мл суга – 2 лимон, 3 аш кашыгы кукуруз крахмалы, 100 г шикәр кирәк. Цедрасын әрчеп алып, лимоннарның согын сыгалар. Цедраны, әчесен бетерер өчен, кайнар су белән пешекләп һәм вак кына турыйлар да, яртı литр суда кайнатып чыгаралар, сөзәләр. Шикәр кушып, кайнатып чыгаралар, 2 минут пешерәләр. Крахмалны 150 мл суда эретеп, лимонлы ширбәткә кушалар, гел болгатып торып кайнатып чыгара язгач, сүндерәләр. Шуңа сыгылган лимон согын өстиләр, әйбәтләп болгаталар, матур пыяла савытларга бүлеп, өстенә шикәр оны сибәләр, лимон телеме белән бизиләр.

Һәрнәрсә өчен түләргә кирәк

Дөньяда нинди генә үзгәрешләр булса да, кеше үз тормышының күңегелгән бер җайга баруын, йорт җирендә тынычлык һәм иминлек булуын тели.

Бәрәкәт иңәр

Аллаһ Тәгалә безгә бик күп нигъмәтләр биргән. Коръәни Кәримнең «Ән-Нәхел» сүрәсендәге 18 нче аятендә әйтелгәнчә, «Әгәр Аллаһ биргән нигъмәтләрне санап карасагыз, һич санап бетерә алмассыз». Шуларның берсе – яшәү урының, йортың булу. «Аллаһ өйләрегезне сезгә торыр урын кылды» («Ән-Нәхел» сүрәсе, 80 нче аять). Йортта тынычлык һәм иминлек урнашсын өчен нәрсә эшләргә кирәкләген Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең күркәм хәдисләрендә аңлатып калдырган. Мөслим риваятендәге бер хәдистә: «Өйләрегездә «Бәкара» сүрәсен укыгыз, ул сүрә укылган өйдән шайтан кача», – диелә. Икенче риваятьтә исә: «Бәкара» сүрәсен укыгыз, чөнки аны уку – бәрәкәт (иңүгә сәбәп) һәм аны калдыру – үкенеч», – дигән.

Аллаһка ышанган, иман китергән кешенең өе ямьләнә, чөнки өйдә Аллаһны зикер итеп, тәсбих, тәһлилләр әйтелә, Коръән, намаз укыла.

Әйе, чыннан да, йортка Аллаһ сүзе керсә, Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә әйтелгәнчә, өйләр җанланып китә: «Аллаһ зикер ителгән йорт белән Аллаһ зикер ителмәгән йортны үле һәм тере мисалында чагыштырып була» (Мөслим риваяте).

Фәрештә кермәс

Өйгә бәрәкәт иңсен, тынычлык сакланcын өчен, анда сурәтләр һәм этләр булмаска тиеш. «Эт һәм сурәт булган йортка фәрештәләр керми», – дигән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм (Бохари риваяте). Мөслим риваятендәге хәдистә исә болай диелә: «Эт һәм сыннар (һәйкәл, пот) булган йортка фәрештәләр керми».

Динебездә җанлы нәрсәләрнең – кешенең яки хайванның кәгазьгә ясалган яки фотога төшерелгән рәсемен сурәт дип әйтәләр. Гадәттә, «истәлек өчен» дип, стеналарга якыннарыбызның, дусларның шул сурәтләрен эләбез. Матурлык өчен дип, хайваннарның сыннарын куябыз. Өй эчендә асрамакка этләр алабыз... Шул рәвешле, бәрәкәтне бетерә торган гамәл ишекләрен үз кулларыбыз белән ачып куеп, үзебез дә аңламастан, өйдә тынычлык бетүгә, тавыш-гауга чыгуга сәбәпче булабыз. Бу хакта Раббыбыз Коръәндә әйтә: «Алар өйләрен үз куллары белән һәм мөэминнәрнең кулы белән харап иттеләр» («Әл-Хәшер» сүрәсе, 2 нче аять). Шуңа да өебезгә фәрештәләр кереп, изге гамәлләребезне язып торулары, йортта рәхим-шәфкать булуын, ә шайтан-җеннәр ояламавын теләсәк, безгә өебезне шул сурәтләрдән һ.б. нәрсәләрдән чистартып, зикер-гыйбадәтләр кылырга кирәк.

Үз өендә ничек яшәргә икәнен һәр кеше үзе белә әлбәттә. Әмма өебезне нурландырырга теләсәк, Раббыбыз таләп иткән әмерләрне үтәмичә бәхет-сәгадәткә ирешеп булмас. Чөнки Ул – Галәмнәрнең хуҗасы һәм идарәчесе, кеше күңеленә тынычлык салучы һәм барча бәла-казадан саклаучы, шуңа да Аңа буйсыну үзебез өчен кирәк.

Сораулар борчыса...

Аллаһ безгә, хайваннардан аермалы буларак, фикер йөртү өчен акыл биргән. Ә без шуны кулланабызмы? Бу дөньяда ни өчен яшәвебез турында уйланабызмы? Әллә бернәрсә хакында да уйламыйча, ашау-эчүне һәм нәсел калдыруны гына кайгыртып яшибезме?.. Әмма акыл нигъмәте белән нигъмәтләндерелмәгән хайваннар да нәкъ шул ук нәрсәләрне кайгырта. Раббыбыз Коръәннең бик күп аятьләрендә фикер йөртергә, тирә-яктан гыйбрәт алырга чакыра: «Ул (Аллаһ) – җирне түшәк кебек ясаучы, анда какшамас тауларны, елгаларны барлыкка китерүче һәм Ул – җимешләрнең һәрберсен, үз орлыкларыннан пар-пар итеп яратучы. Төн белән көнне каплаучы. Фикерле белгәннәр өчен бу хикмәтләрдә гыйбрәтләр (дәлилләр) бар» («Әр-Рәгыд» сүрәсе, 3 нче аять). Ничек төгәл итеп көн артыннан төн кабатлана, төннән соң яңа көн туа, бер көн дә үз вакытыннан соңармый, кояш та чыкмый-яктырмый калмый. Болар тиктомалдан гына түгел бит. «(Аллаһ) сезнең өчен игеннәр, зәйтүннәр, хөрмә агачлары, йөзем һәм җиләк-җимешләрнең һәрберсен үстерде. Боларда, башында фикере булган кеше өчен, әлбәттә, Аллаһның барлыгына, Аның чиксез кодрәтенә дәлил бар. Төнне, көнне, кояшны, айны сезнең өчен бар итте. Йолдызлар да Аның әмеренә буйсына. Хактыр, боларның башында акылы булган һәркем өчен гыйбрәтләр бар. Сезнең өчен Җир өстен дә төрле төстә (чәчәкләр, үсемлекләр) яратты. Үгет алырдай зиһенлеләргә монда, әлбәттә, исбат-дәлил бар» («Ән-Нәхел» сүрәсе, 11-13 нче аятьләр).

> **Хәдис**
>
> ***Бер кеше башкасын гөнаһта гаепләсә, яки аңа кәфер дип әйтсә, кардәше андый булмаса, бу сүзләр әйтүченең үзенә кайтачак.***
>
> **(Сахих Бохари, 6045).**

Рәхмәтле булыйк

Раббыбыз кешелек дөньясына күпме нигъмәт биргән, Җир шарын кешеләргә (хезмәт итәргә) буйсындырган. Бер хакыйкатьне бик яхшы беләбез: бернәрсә дә бушка бирелми. Һәрбер нәрсә өчен түләргә кирәк. Кибеткә кереп кирәк-ярак алсак, кассага барып акча түлибез. Ә менә Аллаһ биргән нигъмәтләрне кулланабыз, тик шөкер итеп рәхмәтле булырга тиешлегебез турында уйламыйбыз. Бушка кулланып, түләмичә яшәсәк, безне бер көн газапка тартмасларммы?

«Дөреслектә, күкләрнең һәм җирнең яралтылуында, аларның күркәм төзелешендә; төн белән көннең алышынып торуында, ел дәвамында озынлыклары үзгәрүдә, акылга ия булучыларга, Аллаһ Тәгаләнең кодрәтен, хикмәтен һәм рәхмәтен исбатлый торган ачык дәлилләр бар. Алар (шушы ачык дәлилләрне күрә алучылар) Аллаһны басып торып та, утырып та, кырын ятып та искә алалар һәм күкләр белән җирнең яралтылуы турында фикер йөртәләр: «И, Раббыбыз! Син боларны юкка гына яралтмадың. Без Синең барча кимчелекләрдән пакьлегеңне расլыйбыз. Син безне Җәһәннәм уты газабыннан сакла» («Әл-Бәкара» сүрәсе, 190-191 нче аятьләр).

«Син боларны юкка гына яралтмадың» – әйе, Раббыбыз бу дөньяны, һәрнәрсәне бөек максат белән яралтты, уен-көлке өчен бар итмәде. Аллаһ Тәгалә әйтә: «Без җирне һәм күкләрне һәм аларның арасында булган нәрсәләрне уйнап-шаярып, бушка гына бар кылмадык. Без аларны хаклык белән яраттык, ләкин аларның күбесе (бу хакыйкатьне) белмиләр» («Әд-Духан» сүрәсе, 38-39 нчы аятьләр). Фикер йөртүчеләр өчен бу аятьтән бик күп файдалар табып була. Күк, җир һәм башка барлык нәрсәләр күңел ачу, уйнау, ашау-эчү, үрчү өчен генә яралтылмаган. Күп очракта без: «Ничек телибез, шулай яшибез. Үләсең дә котыласың, бүтән берни дә булмый», – дип фаразларга яратабыз. Шулаймы икән соң? Аллаһ искәртә: «Сезне күңел ачар өчен яралттык һәм Безгә кайтарылмаячакбыз дип санадыгызмы әллә?» («Әл-Муъминүн» сүрәсе, 115 нче аять).

Шөкер итик

«Без аларны хаклык белән яраттык», – ди Раббыбыз. Ә нинди хаклык белән, нинди максат белән безне бу дөньяга китергән Ул? Аллаһ Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: «Мин кешеләрне һәм җеннәрне бары тик Үземә генә гыйбадәт кылсыннар өчен барлыкка китердем» («Әз-Зарият» сүрәсе, 56 нчы аять). Димәк, максатыбыз – безне барлыкка китергән, безгә күрү, ишетү һәм сөйләшү сәләте биргән, яңгырын яудырып, чишмәләрдән сулар агызып эчәргә су бирүче, суларга һавасын, ашарга ризыгын, урман-кырларда төрледән-төрле җиләк-җимеш һәм күп нигъмәт бүләк иткән Аллаһ Тәгаләгә шөкер итеп гыйбадәт кылу икән ләбаса!

Берәрсе безгә бүләкләр бирсә, без аның һәрбер теләген, һәр кушканын үтәргә тырышабыз. Шулай булгач, безгә гомер һәм барлык нәрсәне биргән Раббыбызга карата да рәхмәтле булырга, Аңа шөкер итәргә тиеш булабыз түгелме?! Коръәннең «Әл-Бәкара» сүрәсендә (243 нче аять) «Дөреслектә, Аллаһ – кешеләргә фазыйләт (рәхмәт) ияcе, әмма кешеләрнең күпчелеге (тиешенчә Аңа) шөкер итми», – диелгән. Чынлап та, берәрсе һәрвакыт кайгыртып, сорағанныбызны биреп торса, аның сүзен тыңлыйбыз. Кешенең холкы шундый: яхшылыкка яхшылык белән җавап бирергә тырыша. Чөнки шулай эшләмәсә, ул үзен игелекнең кадерен белмәгән кеше итеп тоячак. Андый хис-тойгы белән яшәве авыр.

Бу тормышта безне борчыган сорауларның барысына да Аллаһ Коръәндә җавап биргән. «Ул үлемне һәм тереклекне бар кылды – йөкләмәләр йөкләп сезне сынар өчен, кайсыларыгызның яхшырак гамәлле икәнлеген белер өчен», – диелә бит «Әл-Мүлк» сүрәсенең 2 нче аятендә. Шуны онытмасак, тормышыбызны яшәеш кануны булган Коръәнгә нигезләнеп алып барсак иде.

Раил ФӘЙЗРАХМАН,
Балык Бистәсе районының Тәберде Чаллысы мәчете мөгаллиме.
«Догалы өй».

Хикмәтле каләм

Өстәл өстендә каләм белән бабасының нидер язганын игътибар белән оныгы күзәтә.

– Бабай, син минем турында язасыңмы әллә? – дип сорый оныгы.

– Дөрес фикерлисең, әлбәттә, синең турында язам, – ди елмаеп бабасы, – иң мөһиме, нәрсә язуда түгел, ә нәрсә белән язуда. Үсеп җиткәч, син дә шушындый каләм кебек булырсың, дип уйлыйм.

Малай каләмгә зур игътибар белән карап тора, әмма ниндидер үзенчәлекне күрми. Бу каләм дә башкалары шикелле бит, бернинди үзенчәлеге юк.

– Барысы да әйбергә ничек караудан тора. Каләмнең биш төрле яхшы үзлекләре бар. Алдагы гомереңне уңайлы үткәрү өчен, алар сиңа бик кирәк!

Беренчедән, син даһи кеше булырга мөмкинсең, әмма юнәлеш бирүче кулны онытма. Аны без Аллаһ Тәгалә кулы дип атыйбыз. Һәрвакыт аның кодрәтенә ышан.

Икенчедән, каләм белән язу өчен, аны һәрвакыт очлап торырга кирәк. Аның өчен ул авыртудыр, ләкин шуннан соң ул нечкә язачак. Шуңа күрә авыртуга түзәргә туры килә, аны үз файдаңа икәнен онытма!

Өченчедән, әгәр нәрсәне булса да ялгыш язсаң, аны бетергеч белән сөртеп, төзәтеп була. Төзәтү – начар нәрсә түгел. Тормышыңдагы ялгышны тәүбә итеп төзәткән кебек.

Дүртенчедән, каләмнең төп өлеше аның агачы, аның формасы түгел, ә уртасындагы графиты (кара ташы). Синең тәнең эчендәге калебең, иманың кебек. Шуның өчен калебеңне, иманыңны һәрвакыт сакла.

Бишенчедән, каләм һәрчак үзеннән соң эз калдыра. Тормышта төрле хәлләрне чишкәндә син дә үзеңнән соң эз калдырасың. Шуның өчен һәр адымыңны уйлап ясa, синең турында башкаларда яхшы фикер генә калсын! Иманлы бул!

Усаллыктан котылу юлы

Мәдрәсәдә дәресләр тәмамланды. Бер шәкерт үзенең остазы янына килеп:

– Остазым, син – бик зирәк кеше. Кәефең һәрчак яхшы, беркайчан ачуың да килми. Мине дә шундый булырга өйрәтегез әле, – диде.

Остаз риза булды һәм шәкерткә бәрәңге белән үтә күренмәле пакет алып килергә кушты.

Икенче көнне шәкерт остазы сораган нәрсәләрне алып килде. Остаз шәкерткә:

– Әгәр берәр кешегә ачуың килсә, яки аңа үпкәләсәң, бәрәңгене ал да бер ягына үзеңнең исемеңне, икенче ягына ачуланышкан кешенең исемен яз, аннары бәрәңгене пакетка сал, – дип әйтте.

– Шул гынамы? – диде шәкерт.

– Юк, – диде остазы, – син ул пакетны үзең белән йөртергә тиешсең. Әгәр тагын кем беләндер ачуланышсаң, аларны да бәрәңгегә язып, пакетыңа салып куярга тиешсең.

Күпмедер вакыт узганнан соң, бәрәңгеләр шактый артты һәм күтәреп йөрергә авыр була башлады. Шуның өстенә элегрәк салынган бәрәңгеләр бозылып начар исләр дә килә, башкалар алдында шундый килеш йөрү оят. Бүтәннәр сасы истән борынын җыера...

Шәкерт остаз янына килеп, хәлләрне аңлаткан.

– Бу пакетны үзем белән күтәреп йөрү мөмкин түгел. Беренчедән, пакет бик авыр, икенчедән, бәрәңге бозылып бетте. Моны башка нәрсә белән алыштырып булмасмы? – дип сорады шәкерт. Остазы аңа:

– Менә шундый ук хәлләр синең калебеңдә дә. Берәр кешегә ачуың килә икән яки үпкәләсәң, калебеңдә авыр таш барлыкка килә. Баштарак аны сизмисең, ә аннан соң, ташларың күбәя башлый. Башкарган гамәлләреңгадәткә әйләнә, ә гадәтең белән холкың начар якка үзгәрә. Ул ташлар арта бара, сине аска өстери, хәләтеңә дә, сәламәтлегеңә дә зур зыян китерә.

Мин сиңа шул халәтнең ничек булуын читтән торып күрсәтергә мөмкинлек бирдем. Берәр кеше белән ачуланышканчы яки үпкәләшкәнче уйла: ул ташларны күтәреп йөрисең киләме? – дип йомгаклаган сүзен остаз.

Гамәлдә барысы да күренә

Мәдрәсәнең бер сыйныфында дәрес башлангач, остаз шәкертләргә болай дигән:

– Бүгенге дәресебез гамәли булачак. Сезнең белән көндәлек эчә торган чәй турында сөйләшербез, аның файдалы үзлекләрен өйрәнербез, – дип әйткән. Шәкертләр өйрәнә торсын өчен, берничә кап чәй биреп калдырган. Остаз үзе башка бүлмәгә кереп, Коръән укырга керешкән. Бераздан укуын тәмамлап, ул шәкертләр янына чыккан. Чәй турындагы фикерләрен алардан сорый башлаган.

– Монда «ак торна башын юа», диелгән, – дип җавап биргән бер шәкерт. Бу – чәй ясаганчы, чәйнекне кайнар су белән пешекләү, – дигәнне аңлата, – дигән ул.

– Монда «бу чәй зур сарайга керә», – дип язылган. Бу – чәйне чәйнеккә сал, – дигәнне аңлата дигән икенче шәкерт.

– Монда «чәй агымы чәйнекне җылыта», – диелгән. Бу – кайнаган суны чәйнеккә агыз, дигәнне аңлата, – дип әйткән өченчесе.

– Монда «язгы җил биткә өрә», – дип язылган. Бу чәйнең күбеген җыеп ал, дигәнне аңлата, – дигән дүртенче шәкерт.

Шәкертләр бер-бер артлы үзләренең чәй турындагы фикерләрен остазга җиткергәннәр. Бер шәкерт берни әйтми утырган. Ул чәйнекне алып кайнар су белән пешекләгән, аннары чәй салып, пешереп чынаякка салган һәм остазының каршысына китереп куйган.

– Синең хикәяң иң яхшысы булды, – дигән остаз бу шәкерткә, – син миңа тәмле чәй эчердең һәм төп кагыйдәне үтәдең. Анда болай язылган: «Нәрсә язылганы турында сөйләмә, нәрсә аңлаганыңны күрсәт», – диелгән.

– Остазым, бу шәкерт чәй турында берни дә сөйли алмады бит, – дигән бер шәкерт.

– Кешенең кылган гамәле, аның сөйләвенә караганда үтемлерәк әйтә, – дип тәмамлаган остаз.

Нияз БИШБАЛТА әзерләде.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

27 гыйнвар – «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт).
28 гыйнвар – 12.00, 12.30 – «Дәрсе гыйбрәттер театр...» (Р.Мөхәммәтшин). 17.00 Шәрык клубында – «Безнең шәһәрнең серләре» (Г.Камал). 18.00 – «Санаулы кичләр» (А.Володин).
29 гыйнвар – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).
30 гыйнвар – Әлмәт татар дәүләт драма театрының «Ул әле өйләнмәгән иде» спектакле (Г.Исхакый).
31 гыйнвар – «Рәшә» (Ә.Еники).
1 февраль – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
2 февраль – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).
3 февраль – 17.00 Шәрык клубында – «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт). 19.00 – «Дон Жуан» (Ж.-Б. Мольер).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

30 гыйнвар – 28 февраль – Ф.Шаляпин исемендәге XLI халыкара опера фестивале:
30-31 гыйнвар – «Севильский цирюльник» (Дж. Россини).
1 февраль – С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт зур концерт залында – Ф.Шаляпинның 150 еллыгы уңаеннан «Ерак илләр турында төшләр» дип исемләнгән камера музыкасы концерты.
2 февраль – Казан Ратушасында – «Ике зур шәхес. Шаляпин һәм Горький» исемле әдәби-музыкаль спектакль.
3 февраль – «Тоска» (Дж.Пуччини).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

27 гыйнвар – Премьера. «Идегәй».
28 гыйнвар – «Кияү урлау» (С.Юзеев, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
29 гыйнвар – «Утка очкан кубәләктәй» (Н.Гыйматдинова, Т.Хәләф инсценировкасы).
31 гыйнвар – 13.00 – «Беренче театр» (Г.Камал). 18.30 – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
1 февраль – «Беренче мәхәббәт» (И.Гали).
2 февраль – «Гомер буе сине көтәм» (И.Мәхмүтова).
3 февраль – «Мәдинә» (И.Зәйниев).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

28 гыйнвар – Театрның вокал буенча мөгаллиме Лилия Зәйнуллинаның юбилей кичәсе.
1 февраль – «Рөстәм маҗаралары» (аталы-уллы Гадел һәм Рөстәм Кутуйлар әсәре, А.Әхмәдиев инсценировкасы).
2 февраль – «Сәлам, Актәпи!» (А.Сальникова).
3 февраль – «Мио, минем Мио!» (А.Линдгрен).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

27 гыйнвар – «Маугли» (Р.Киплинг).
28 гыйнвар – зур залда – «Маугли» (Р.Киплинг). Кече залда – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
29 гыйнвар – зур залда – «Волк и семеро козлят» (Э.Гыйлемханова инсценировкасы). Кече залда – «Мактанчык әтәч» (Аманулла).
31 гыйнвар – «Бобровый пруд» (Н.Сладков, А.Гыймаев инсценировкасы).
2 февраль – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
3 февраль – Премьера. «Аладдин».

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

30 гыйнвар – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Фәйзрахмановның туган көненә багышланган концерт һәм «Юлын белгән – адашмас» китабын тәкъдим итү. Кичәдә Ф.Каһиров, А.Хәйри, С.Зәйнетдинова, Алинә һәм Азат Кәримовлар, Р.Насыйбуллин, И.Мөһетдинов, Татарстан фольклор музыкасы дәүләт ансамбле катнаша.
31 гыйнвар – Филармониянең В.Васильев җитәкчелегендәге әдәби-музыкаль лекторие артистлары башкаруында композитор Салих Сәйдәшевкә багышлау концерты. Программада – «Әдрән диңгез», «Кара урман», «Җырларым», «Зәңгәр шәл», «Наемщик», «Кандыр буе» спектакльләреннән арияләр һ.б.
2 февраль – Татарстан Республикасының А. Шутиков җитәкчелегендәге халык музыка уен кораллары оркестрының оперетта һәм мюзикл жанрларына багышланган музыкаль агарту программасы. Мәскәүдән җырчылар Ю.Гончарова һәм М.Катырев катнаша.
3 февраль – «Мастер и Маргарита» спектакле.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

27 гыйнвар – «La Primavera» Казан камера оркестрының яшь талантлы музыкантлар өчен оештырылган «Звезды из завтра» республика иҗат программасы.
28 гыйнвар – Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестры концерты. Дирижер – А.Сладковский.
29 гыйнвар – 11.00, 13.00 – Балалар өчен «Lego Music» исемле музыкаль программа.
30 гыйнвар – Башкортстан Республикасы милли симфоник оркестры концерты. Дирижер – Башкортстанның атказанган артисты Д.Крюков. Солист – Башкортстанның халык артисты А.Назиуллин (кларнет).

“Коры” кабилә

Амазонка елгасы буенда такейра кабиләсе яши. Цивилизациянең ни икәнен дә белмәүче бу гаҗәеп җан ияләренең тән тиресе һәм чәче бер дә юешләнми. Аларның өстенә суны хәтта тонналап сипсәң дә коп-коры калачаклар. Дымлы урман шартларында яши алсыннар өчен, Аллаһ Тәгалә аларның тиресен үзенчәлекле япма белән каплаган. Бу кабиләне 1988 елда Амазонка буйлап сәяхәт иткәндә, француз табибе Жак Толборн таба. Коеп яуган яңгыр сәяхәтен дәвам итәргә комачаулагач, доктор юл өстендәге бер авылда туктарга мәҗбүр була. Җирле халыкның искиткеч көчле яңгыр астында тыныч кына эшләп йөрүен күргәч, Толборнның исе китә. Доктор кабилә вәкилләренең тән тиресе төзелешен өйрәнергә керешә һәм аның суга, дымга каршы торучан матдә белән капланганлыгын ачыклый.

(“The Mirror”).

Сихәт диңгезе саега

